— изучение практики формирования и оформления дел, порядка их использования;
— составление номенклатуры дел;
— назначение ответственных за формирование и ведение дел в структурных подразделениях;
— изучение порядка регистрации документов и подготовка предложений по использованию персонального компьютера;
— ведение ежегодной обработки документов предприятия для передачи их в архив или на уничтожение;
— внедрение средств оргтехники (ПК, факс, ксерокс и т.д.);
— внедрение современных информационных технологий на базе электронной техники (компьютерное делопроизводство, электронная почта);
— составление инструкции по документационному обеспечению предприятия;
— обучение сотрудников предприятия навыкам рациональной работы с документами и современными информационными технологиями.

# Сәркатиплек эше

## КЕРЕШ

**Сәркатиплек эшләре буенча әлеге кулланма «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Законны гамәлгә ашыру максатында ике дәүләт телендә дә төзелде.**

Хәзерге заман учреждениесен сәркатиптән башка күз алдына да китереп булмый. Сәркатипнең төп вазифасы:

— җитәкче хезмәткәрләрнең эшен оештыруны яхшыртудан һәм аның нәтиҗәлелеген күтәрүдән;
— оешманың җитәкчесе белән башка әгъзалары арасында арадашчы булудан гыйбарәт.

Сәркатип — учреждениенең йөзе. Аның һәр эше мөһим. Хаталы язу, җыйнаксызлык, хатларны дөрес адреска һәм вакытында җибәрмәү, оныту, саксызлык эшкә зур зыян китерергә мөмкин.

«Сәркатиплек эше» предметы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

— илебездә эш кәгазьләре үсешенең һәм формалашуының тарихын өйрәнү;
— бүлекчә хезмәткәрләренең эшен оештыру нигезләре;
— документациягә бәйле төрле гамәлләрне оештыру, автоматлаштыру принциплары;
— документлы һәм документсыз хезмәт күрсәтү;
— эшлекле аралашу нигезләре.

Әлеге курсның максатлары:

— документлар белән эшләүнең җәмгыять тормышындагы әһәмиятен күрсәтү;
— булачак сәркатипләрдә башкарылган эш өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.

## ДОКУМЕНТАЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ

Борынгы заманнардан алып хәзерге көнгәчә илебезнең тарихын, шул заманнардагы көнкүрешнең һәм башка мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген өйрәнү мөмкинлеге бирә торган төрле документлар сакланган. Документлар, борынгы язмалар белән беррәттән, мөлкәти мөнәсәбәтләрне чагылдыру чарасы буларак барлыкка килгән.

Язу даирәсе киңәйгән саен, алар да аралашу һәм мәгълүмат алмашу чарасына әвереләләр. Документлар — кеше хәтеренең көзгеләре, тарих хәбәрләре.

Борынгы бабаларыбыз хакындагы тарихи чыганаклардан билгеле булганча, Алтын Урда чорында ук хан хөкүмәтендә дәүләт сәркатибе (битекче) дигән дәрәҗә булган.

XV гасыр ахырында дәүләт хакимияте кенәзлек идарәсенең аерым тармакларын җитәкләүче үзәк органнар — беренче боерыклар һәм дәүләт идарәсенең урыннардагы органнары — боерык бирү ызбалары барлыкка килә. Боерыклар системасын рәсмиләштерү ил белән идарә итүне үзәкләштерергә мөмкинлек бирә.

Әлеге органнар эшчәнлегендә боерыклар белән эш башкару дип аталган хезмәт органы оеша. Боерыклар идарә итү, салымнар җыю һәм суд эшләренә карый.

Петр I үткәргән үзгәртеп корулар вакытында шундый төрдәге 50 хезмәт органы була. Шул ук вакытта старосталар, городничийлар идарә итүендәге җирле һәм губерна хезмәт ызбалары барлыкка килә.

Боерыклар системасына алмашка 1717—1718 елларда 12 коллегия оештырыла, алар билгеле бер тармак яисә идарә итү өлкәсенә карый һәм Сенатка буйсына. Дәүләт коллегияләренең 1720 елның 27 февралендә Петр I имза салган Генераль регламенты коллегияләр структурасын тулысынча билгели.

Әлеге документта коллегиянең һәр бүлекчәсе вазифасы җентекләп күрсәтелә, канцелярия структурасы һәм эшчәнлеге хакында, шулай ук сәркатиплек чины турындагы бүлек барлыкка килә.

Коллегиаль эш башкару боерыклар нигезендә эш башкару белән чагыштырганда кулайрак була, теркәү системасы тәртипкә китерелә. Теркәү махсус журналларда алып барыла. Югары инстанцияләрдән алынган документлар аерым журналда билгеләнә, җибәрелә торган документлар өчен аерым теркәү журналлары була.

Коллегиядә барлыгы 4 теркәү журналы алып барыла:

— А һәм В — югары органнар өчен документларны теркәү;

— С һәм Д — калган барлык документларны теркәү.

Коллегиаль эш башкару чорында «архив» дигән атама барлыкка килә.

XVIII—XIX гасырларда Россия феодаль-крепостной дәүләт була. 1802 елда Петр I төзегән коллегияләрне министрлыклар итеп үзгәртү турында боерык басылып чыга. Министрлыкларны төзү турындагы әмер җитәкче чиновникларның компетенция чикләрен билгели. Алар, биләгән эш урыннарына бәйле рәвештә, документларның кайбер төрләрен генә алырга һәм имзаларга хаклы булалар.

Министрлыклар барлыкка килгәч, башкарма хакимият органнары функцияләре төгәл ачыклана, коллегиальлек бердәм башлангыч белән алмашына. Бу — дәүләт аппаратының үзәкләштерелүенә китерә.

1812 елда 8 министрлык төзелә. Тигез дәрәҗәдәге учреждениеләр үзара мәгълүматлар һәм рәсми хатлар алмашалар.

Хезмәтара язма хәбәрләшү өчен почмаклы штамп куелган бланклар кулланыла. Документларның төрле инстанцияләрне узу тәртибе закон белән катгый рәвештә регламентлана. Керүче һәм чыгучы документлар журналда теркәлә. Эшләр түбәндәге 3 категориягә бүленә:

— кичектергесез эшләр;

— гадәти эшләр;

— агымдагы эшләр.

1840 елның 23 мартында Петербург шәһәренең Путилов һәм Невский машина төзелеше заводларының беренче җитәкчеләренә шәхси сәркатип ярдәмче вазифалары билгеләнә. Бу көнне Россиядә профессиональ сәркатипләр хезмәтенең рәсми рәвештә барлыкка килгән көне дип санарга була.

## ЭШ БАШКАРУНЫҢ НОРМАТИВ-ЫСУЛЫЙ БАЗАСЫ

### Эш башкаруның норматив-ысулый базасы составы

Эш башкаруның норматив-ысулый базасы — учреждениенең агымдагы эшчәнлегендә документларны төзү, эшкәртү, саклау һәм куллану технологиясен регламентлаучы; шулай ук эш башкару хезмәтенең эшчәнлеген: структурасын, функциясен, штатларын, техник тәэминатын һәм кайбер башка аспектларын регламентлаучы законнар, норматив-хокукый актлар һәм ысулый документлар җыелмасы ул.

Эш башкаруның норматив-ысулый базасы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

— Россия Федерациясенең мәгълүмат һәм документлар өлкәсендә закон чыгару актлары;

— Россия Федерациясе Президенты әмерләре һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль дәрәҗәдә документлар белән тәэмин итү мәсьәләләрен регламентлаучы карарлары һәм боерыклары;

— башкарма хакимият федераль органнарының (министрлыклар, комитетлар, хезмәтләр, агентлыкларның һ.б.) гомумтармак һәм ведомство характерындагы хокукый актлары;

— Россия Федерациясе субъектларының яисә территория берәмлекләренең вәкиллекле һәм башкарма органнарының эш башкару мәсьәләләрен регламентлаучы хокукый актлары;

— учреждениеләрнең, оешмаларның һәм предприятиеләрнең норматив һәм тәгълимнамә характердагы хокукый актлары, эш башкару буенча ысулый документлары;

— документлар өчен дәүләт стандартлары;

— документларның бердәйләштерелгән системалары;

— техник-икътисади һәм социаль мәгълүматның гомумроссия классификаторлары;

— идарә итүне документлар белән тәэмин итүнең Дәүләт системасы. Документлар белән тәэмин итү хезмәтләренә төп таләпләр;
— идарә итү хезмәтен оештыру һәм хезмәтне саклау буенча норматив документлар;
— документларны архивта саклауны оештыру буенча норматив документлар.

## Документларга дәүләт стандартлары

Стандартлаштыру Россия Федерациясенең «Стандартлаштыру турында» 1993 елның 10 июнендә кабул ителгән Законы нигезендә нормаларны, кагыйдәләрне һәм тасвирнамәләрне билгеләү эшчәнлеген аңлата. Ул түбәндәге максатларга хезмәт итә:

— продукциянең, эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең әйләнә-тирә мохит, тормыш, сәламәтлек һәм мөлкәт өчен куркынычсызлыгы;
— продукциянең техник һәм мәгълүмати ярашуы, үзара алмашучанлыгы;
— фән, техника, технологиянең үсеш дәрәҗәсенә карап, продукциянең, эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты;
— барлык ресурс төрләрен экономияләү.

Документларның бердәйләштерелгән системасы һәм техник-икътисади мәгълүматны классификацияләү һәм кодлаштыруның бердәй системасы стандартлары түбәндәге мөстәкыйль комплексны тәшкил итә:

— ГОСТ 16487—83 — Эш башкару һәм архив эше. Терминнар һәм билгеләмәләр (ГОСТ 1970 елда беренче терминология стандартын теркәгәндә бирелгән номерын саклый);
— ГОСТ 6.10.3—83 — Документларның бердәйләштерелгән системасы. Коммуникатив форматтагы бердәйләштерелгән документларның мәгълүмат язмасы;
— ГОСТ 6.10.4—84 — Документларның бердәйләштерелгән системасы. Исәпләү техникасы чаралары белән төзелгән машина чыганакларындагы һәм машинограммалардагы документларга юридик көч бирү. Төп нигезләмәләр;
— ГОСТ 6.01.1—87 — Техник-икътисади мәгълүматны классификацияләүнең һәм кодлаштыруның бердәй системасы;
— ГОСТ 6.10.5—87 — Документларның бердәйләштерелгән системасы. Үрнәк рәвеш булдыруга таләпләр;
— ГОСТ 6.10.6—87 — Тышкы сәүдә документларының бердәй системасы. Үрнәк форма;
— ГОСТ 6.10.7—90 — Тышкы сәүдә документларының бердәй системасы. Исәп;
— ГОСТ Р 6.30—97 — Документларның бердәйләштерелгән системасы. Оештыру-боеру документлары системасы. Документларны тутыруга таләпләр.

## Документларның бердәйләштерелгән системалары

Учреждениеләр эшчәнлегендә кулланылучы документларның санын киметү, рәвешләрен бердәйләштерү, әзерләү һәм эшкәртүгә хезмәт, вакыт һәм матди чыгымнарны киметү максатларында, документларны бердәйләштерү һәм аларның бердәйләштерелгән системасын булдыру эшләре алып барыла. Документларның бердәйләштерелгән системасын (ДБС) булдыру нигезендә камилләштерү ысулы — идарә итү документлары составының һәм формаларының бердәй рәвешен билгеләү ята. Хәзерге вакытта гамәлдә түбәндәге сигез ДБС бар:

— оештыру-боеру документларының бердәйләштерелгән системасы;
— банк документларының бердәйләштерелгән системасы;
— бюджет учреждениеләре һәм оешмаларының финанс, исәп-хисап документларының бердәйләштерелгән системасы;
— хисап-статистика документларының бердәйләштерелгән системасы;
— предприятиеләрнең исәп-хисап буенча бухгалтерлык документларының бердәйләштерелгән системасы;
— хезмәт документларының бердәйләштерелгән системасы;
— Россия Федерациясе Пенсия фонды документларының бердәйләштерелгән системасы;
— тышкы сәүдә документларының бердәйләштерелгән системасы.

Документларның бердәйләштерелгән системасын әзерләү белән әлеге эш йөкләнгән министрлыклар һәм ведомстволар шөгыльләнә.

## Техник-икътисади һәм социаль мәгълүматның гомумроссия классификаторлары

Техник-икътисади һәм социаль мәгълүматның гомумроссия классификаторлары мәгълүмат белән тәэмин итүдә мөһим чаралар булып торалар. Алар автоматлаштырылган системаларда мәгълүматларны эшкәртүне тәэмин итәләр.

Техник-икътисади һәм социаль мәгълүмат классификаторлары — кодлар куелган һәм классификация төркемчәләре рәвешендә тәкъдим ителгән объектлар исемнәренең системага салынган җыелмасын үз эченә алган норматив документлар ул.

Куллану өлкәсеннән чыгып, классификаторлар гомумроссия, тармак һәм предприятие классификаторлары дигән төрләргә аерыла. Эчтәлеге ягыннан барлык классификаторлар түбәндәге төркемнәргә бүленә:

1. Автоматлаштырылган идарә итү системасында хәл ителүче документлар, мәсьәләләр, эшчәнлек төре, икътисади һәм социаль күрсәткечләр турындагы мәгълүмат классификаторлары.
2. Оештыру структуралары турындагы мәгълүмат классификаторлары.
3. Халык һәм кадрлар турындагы мәгълүмат классификаторлары.

Техник-икътисади һәм социаль мәгълүмат классификаторының структурасы һәм эчтәлеге Идарә документларының гомумроссия классификаторы мисалында түбәндәгечә чагыла.

Идарә документларының гомумроссия классификаторы документларның бердәйләштерелгән системасы һәм халык хуҗалыгында куллану рөхсәт ителгән документ формалары турындагы мәгълүматны үз эченә ала. Ул түбәндәге максатларга хезмәт итә:

— документ формаларын теркәү;
— халык хуҗалыгында мәгълүмат агымын тәртипкә салу;
— кулланылучы формаларның санын киметү;
— документларның бердәйләштерелгән формаларын әйләнештән алу;
— бердәйләштерелгән формаларны исәпкә алу һәм системалаштыруны тәэмин итү;
— документларны теркәү нигезендә исәпкә алу һәм системалаштыру;
— идарә итү өлкәсендә кулланылучы документларның составын тикшереп тору һәм мәгълүматның кабатлануын булдырмау;
— документларның бердәйләштерелгән формаларын куллануны контрольдә тотуны нәтиҗәле итеп оештыру.

Идарә документларының гомумроссия классификаторы Россия Федерациясе министрлыклары (ведомстволары) — ДБСны төзүчеләр тарафыннан раслана торган документларның бердәйләштерелгән гомумроссия (тармакара, ведомствоара) формалары классификация объектлары булып торалар.

Идарә документларының гомумроссия классификаторы бердәйләштерелгән документ формасының коды җиде санлы унарлы билгедән һәм контроль санынннан тора.

Идарә документларының гомумроссия классификаторында өч баскычлы иерархик классификация кабул ителгән.

Классификаторның һәр позициясе ике блоктан тора:
— тәңгәлләштерү блогы;
— классификация объекты исемнәре блогы.

Бердәйләштерелгән форма классификация аша тәңгәлләште- реләә.

Идарә документларының гомумроссия классификаторында бердәйләштерелгән документ формасының коды түбәндәгечә билгеләнә: XX XX XXX X.

Баштагы ике билге — формаларның классын, аннан соңгы ике билге — формаларның ярдәмче классын, аннан соңгы өч билге —теркәү номерын, соңгы билге контроль санын аңлата.

Мәсәлән, Пенсия фондына иминият кертемнәре буенча исәп-хисап коды — 09010046.

Ул түбәндәгечә укыла:

— 09 — Пенсия фонды документларының бердәйләштерелгән формасы;
— 01 — акчаларны исәпкә алу һәм бүлү документлары;
— 004 — Пенсия фондына иминият кертемнәре буенча исәп-хисап ведомосте;
— 6 — контроль саны.

Бердәйләштерелгән документ формасының кодлы билгеләнешендә классификациянең түбәндәге билгеләре чагылдырыла:

— беренче һәм икенче тамгалар (формаларның классы) — бердәйләштерелгән документ формасының документларның бердәйләштерелгән тиешле системасына каравы;
— өченче һәм дүртенче тамгалар (формаларның ярдәмче класслары — подкласслары) — күптөрле документ формаларының эчтәлек ягыннан берлеге һәм аларны куллану максаты;
— бердәйләштерелгән документ формасының бишенче, алтынчы, җиденче тамгалары — ярдәмче класс эчендәге теркәлү номеры;
— сигезенче тамга — контроль саны.

Классификация объекты исемнәре блогы — бердәйләштерелгән документ формасының төгәл исеме язмасы.

Идарә документларының гомумроссия классификаторы кодлар ГОСТ Р 6.30—97 «Документларның бердәйләштерелгән системасы. Оештыру-боеру документлары системасы. Документларны тутыруга таләпләр» нигезендә бердәйләштерелгән документ формаларында куела.

ЭШ БАШКАРУ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ
ЭШЕН ОЕШТЫРУ НИГЕЗЛӘРЕ

Документлар, рәсми кәгазьләр белән эш итү хезмәте хезмәткәрләренең эшен оештыру — коллектив белән идарә итү ысуллары, стиле һәм системасын күздә тота, коллективның югары җитештерүчәнлек белән нәтиҗәле эшләве өчен уңай эш шартлары тудыра. Хезмәтнең дөрес оештырылуы югары җитештерүчәнлеккә турыдан-туры бәйле.

Документлар һәм рәсми кәгазьләр белән эш итү хезмәте хезмәткәрләренең эшен оештыру түбәндәгеләрне үз эченә ала:

— хезмәт шартлары тудыру;
— документлар белән эш итү (канцелярия) хезмәтен төгәл оештыру, документлар белән эш итүнең иң кулай формаларын сайлап алу;
— аерым башкаручылар һәм бүлекчәләр арасында аларны классификацияләү эшчәнлеге чикләрен дөрес билгеләү;
— документлар белән эш итү хезмәте хезмәткәрләренең вазифаи һәм исәп составын билгеләү;
— эштә белгечлек һәм культура дәрәҗәсен күтәрү.

**Эш урынын оештыру**

Эш урыны — кирәкле хезмәт чаралары белән тәэмин ителгән хезмәт эшчәнлеге өлкәсе ул.

Эш урынын оештыру — эшчәнлек өчен кирәкле әйберләр һәм җайланмалар белән эш урынын җиһазлау һәм аларны югары нәтиҗә бирерлек итеп урнаштыру чаралары системасын булдыру дигән сүз. Эш урынын оештыру өчен түбәндәгеләрне үтәү сорала:

— мебельнең үлчәмен һәм формасын сайлау;
— хезмәткәрләрнең эш урыны уңайлылыгын тәэмин итү;
— эш урынын тиешле оештыру техникасы белән җиһазлау;
— хезмәткәрләрне башкарыла торган эшләр эзлеклелеген исәпкә алып урнаштыру;
— уңай санитария-гигиена һәм эстетик хезмәт шартлары тудыру.

Эш барышында физик көчне кирәкмәгәнгә сарыф итмәс өчен, түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

— эш урынында артык әйбер тотмаска;
— һәр нәрсә үз урынында булырга һәм эш барышында бары тик үз өлкәсендә генә даими күчеп йөрергә тиеш;

— уң кул белән ала торган әйберләрне — уң якка, сул кул белән ала торганнарын — сул якка, еш кулланыла торганнарын — янәшәгә (каләм, кәгазь һ.б.), ә сирәк кулланыла торган бар нәрсәне (сүзлекләр, белешмәлекләр, картотека, документлар салынган папка һ.б.) ераграк куярга.

Эшне планлаштырганда, башкарыла торган гамәлләрнең технологиясе һәм рәвеше; эш барышында үзара бәйләнеш; янгын куркынычсызлыгы һәм сәнәгать санитариясе кагыйдәләре төп фактор булып тора.

Эш урынында чисталык һәм тәртип булдыруның, хезмәт культурасын үтәүнең зарурлыгын һәрвакыт истә тотарга кирәк.

Эш урынын дөрес итеп оештыру көн дәвамында хезмәткәрнең эшләү сәләтен тәэмин итүдә мөһим шарт булып тора.

## Эш кәгазьләре, документлар белән эш итүче хезмәткәрләрнең хезмәт шартлары

Хезмәт шартлары — эш барышында кеше сәламәтлегенә һәм эшләү сәләтенә тәэсир итүче факторлар җыелмасы ул.

Хезмәткәрләр өчен җайлы хезмәт шартлары тудырырга кирәк.

Хезмәт шартларын яхшырту чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

— эш урынында тиешле яктылыкны (гомуми һәм турыдан-туры эш урыннарында) тәэмин итү;
— бүлмәнең (бинаның) чисталыгын тәэмин итү;
— тиешле һава температурасын һәм дымлылыгын тәэмин итү;
— эш бүлмәсенең кәефне күтәрерлек, күңелгә хуш килерлек итеп буялган булуын тәэмин итү;
— тавыш тәэсирен булдырмау;
— дөрес эш режимын урнаштыру.

Яктылык — эш урынында уңайлылык тудыручы шартларның берсе. Бүлмәнең яктыртылуы гамәлдәге норма таләпләренә туры килергә тиеш. Тиешле яктылыкны тәэмин итү өчен ЛБ һәм ЛХБ тибындагы люминесцент лампаларын куллану тәкъдим ителә. Яктыртылуга көн вакыты, стеналарның буявы, яктылык чыганагының чисталыгы да тәэсир итә.

Чисталык — шулай ук мөһим шартларның берсе. Хезмәткәрнең эш өстәле һәрвакыт чиста, пөхтә булырга, өстәлдә эш өчен кирәк булмаган әйберләр ятмаска тиеш.

Эш бүлмәләрендә температура Цельсий буенча + 18—20°, кышкы чорда чагыштырмача дымлылык — 45—50 %, ә җәй айларында 50—55 % булырга тиеш.

Эш бүлмәләрен артык ачык булмаган, тоныкрак төсләргә буяу тәкъдим ителә. Югары температура режимындагы эш бүлмәсен — салкын төскә, ә түбән температуралы эш бүлмәсен җылы төскә буяу максатка ярашлы була.

Эш кәгазьләре белән эш итүче хезмәткәрләрнең эш режимы хезмәт белән ялның билгеле бер чиратлашуын күздә тотарга тиеш.

Хезмәткәрләр өчен һәр 45 минут саен 3—4 минутлык тәнәфес кертелә. Шулай ук көнгә ике мәртәбә физкультура күнекмәләре ясап алу тәкъдим ителә.

## Офисны җиһазлау

Хәзерге офис эшне җиңеләйтүче һәм тизләтүче төрледән-төрле техник чаралар белән җиһазландырылырга тиеш.

Заманча элемтә чаралары:

— радиотелефон — телефон станциясенә чыбыклар аша түгел, радиоканал буенча тоташкан телефон аппараты, аның аша 60—100 чакрым ара ераклыгыннан да сөйләшергә була. Радиотелефонны гадәттә автомобильләргә куялар;
— күзәнәкле радиотелефон. Сөйләшкән чакта, күзәнәкле телефон хезмәт күрсәтү зонасында торган тапшыргыч белән элемтәгә керә. Күзәнәкле телефон бераз зурайтылган телефон трубкасы рәвешендә дә ясалырга мөмкин;
— радиотрубкалы телефон — телефон станциясе белән чыбыклы элемтәгә керүче, трубкасындагы шнур радиолиниягә алыштырылган гадәти телефон;

— радиосузгычлар;
— пейджер — кабул ителгән хәбәрләрне язу экраны булган кечкенә үлчәмле санлы мәгълүматалгыч;
— номерны автомат рәвештә билгеләүчесе булган телефон (НАБлы телефон);
— әбүнәче номерын билгеләү мөмкинлеген ябучысы булган телефон (анти-НАБлы телефон);
— автоҗавап бирүче телефон — хәбәрне язып алучы магнитофон урнаштырылган телефон. Әлеге хәбәр бу телефонга шалтыраткан һәркемгә тапшырыла;
— телефакс — стандарт кәгазь битләрендә әллә ни югары сыйфатлы булмаган сурәт белән мәгълүмат тапшыруга исәпләнгән. Телефакс кәгазь битендәге сурәтне кара һәм ак ноктлалар җыелмасы итеп карый. Кәгазь бите үзенә аркылы урнашкан яктыга сизгер элементлар рәте кырыеннан үтә. Телефаксны кабул итүче мәгълүматның шифрын (эчтәлеген) ача һәм аны факска кертеп эшләнгән басма җайланмага тапшыра. Мәгълүматны тапшыру режимы кул белән башкарыла. Сәркатип факсны кабул итү һәм тапшыру, факс ярдәмендә документлар, эш кәгазьләре күчермәсен алу эшләрен башкарырга тиеш.

Офисны җиһазлаганда, түбәндәгеләрнең булуы шарт:

— күчермәләр алу-күбәйтү техникасы;
— яктылык ярдәмендә күчермәләр алу аппараты;
— электрография басмасы (Rank Xerox);
— трафарет басма (ротатор, ризограф);
— шәхси компьютер.

Офис эчендәге элемтә мини-АТС ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

## Канцелярия структурасы һәм эшчәнлеге

Предприятиеләрдә эш кәгазьләре, документлар белән эшне канцелярия дип аталган хезмәт башкара.

### *Учреждение канцеляриясе турында бердәй нигезләмә*

1. Гомуми нигезләмә.

Канцелярия учреждениедә эш кәгазьләре, документлар белән эшләүне гамәлгә ашыра һәм аның структурасының мөстәкыйль бүлекчәсе булып тора.
Канцелярияне аның мөдире (башлыгы) җитәкли.

2. Канцеляриянең төп бурычлары һәм эшчәнлеге:

— учреждениенең эш кәгазьләре, документлар белән эшләвен оештыру; учреждениегә керә торган, аннан чыга торган һәм эчке документларны үз вакытында карап тикшерүне тәэмин итү;
— боеру рәвешендәге документларны рәсмиләштерү (теркәү) һәм тиешле адресатларына җибәрү, документларның дөрес тутырылуын тикшерү; аларны эш кәгазьләре итеп туплау, хатлар алышуны оештыру;
— хатларны, эш кәгазьләрен кабул итү, теркәү, саклау һәм исәбен алып баруны гамәлгә ашыру;
— эшләрне архивка тапшыру өчен әзерләү;
— шәхси мәсьәләләр белән килүчеләрне кабул итүне оештыру;
— эш кәгазьләре, документлар белән эш итү хезмәте хезмәткәрләрен әзерләүне һәм белгечлеген күтәрүне оештыру.

3. Эшләр канцеляриянең структур бүлекчәләре арасында түбәндәгечә бүленә:

— **секретариат** читтән кергән хатларны, кәгазьләрне карый һәм учреждение җитәкчелегенә җиткерү өчен әзерли; карар проектларын, хатлар, белешмәләр һәм башка документларны, коллегия утырышларына материаллар һ.б. әзерли;
— **эш кәгазьләре, документлар белән эш итүне рациональләштерү бүлекчәсе** учреждение аппаратында эш кәгазьләре, документлар белән эш итү хезмәтен камилләштерү чараларын эшли һәм гамәлгә кертә. Документлаштыру буенча тәгълимнамә эшли; эш төрләре җыелмасын төзи һәм аны җитәкчелеккә кертә;

— **эш башкаруны тикшерүдә тоту бүлекчәсе** эш кәгазьләрен, документларны тикшерүдә тота һәм анализлый, җитәкчелеккә тиешле белешмәләр тутыра;
— **хатлар, эш кәгазьләрен исәпкә алу, җибәрү һәм теркәү бүлекчәсе** гражданнардан кергән гаризалар, хатлар һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм теркәү эшләрен башкара;
— **архив** эшләр тупланмасын кабул итүне, исәбен алып бару һәм саклауны гамәлгә ашыра;
— **корректорлар төркеме белән машинкада басу (компьютерларда җыю) бюросы** эш кәгазьләрен, документларны бастыру эшләрен, басылган материалны тикшерү һәм төзәтү, стенография эшләрен башкара.

ИДАРӘ СТРУКТУРАСЫНДА СӘРКАТИП

Бер генә учреждение, оешма, предприятие, фирма да оештыру-башкару эшчәнлеген тормышка ашыручы җитәкчесез була алмый. Һәр җитәкче исә оештыру һәм мәгълүмат хезмәтен башкаруны үз өстенә алучы сәркатипкә (секретарьга) мохтаҗ.

«Секретарь» сүзе латинча «secretarius» дигән сүздән килеп чыккан һәм башта «ышанычлы зат» дигән мәгънәдә кулланылган. «Сәркатип» сүзе татарчага гарәп-фарсы теленнән кергән, бүгенге көндә «секретарь» сүзе урынына уңышлы кулланыла.

Сәркатип һәр фирмага һәм оешмага кирәк.

Хәзерге көндә махсус урта белемле сәркатипләр саны арта бара. Мәктәпне тәмамлаучылар арасында сәркатип белгечлеген сайлаучылар шактый күп санны тәшкил итә.

***Сәркатип түбәндәгеләрне белергә тиеш:***

— идарә итүнең хокукый нигезләрен;
— административ, хезмәт, хуҗалык хокукын;
— үзе эшләгән оешманың эш тәртибен билгеләүче норматив-хокукый актларны;
— идарә итү нигезләрен;
— илдә һәм үз төбәгендә хакимият һәм идарә органнары системасын;
— үзе эшләгән тармакны, аның бәйләнешләрен;
— үзе эшләгән оешманың вазифасын, бурычларын, структурасын, аның вертикаль һәм горизонталь бәйләнешләрен;
— менеджмент нигезләрен;
— идарә итү хезмәтен фәнни оештыру нигезләрен: идарә итү эшчәнлеген мәгълүмат һәм документлар белән тәэмин итү буенча норматив-ысулый документларны;
— исәпләү һәм оештыру техникасын;
— гомуми социаль психологияне;
— этика һәм эстетика нигезләрен;
— эш башкаруны;
— документларны төзү һәм тутыру ысулларын;
— документлар белән эшләүне оештыруны;
— документлардан тыш хезмәт күрсәтүне;
— архив эшен.

***Сәркатип түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:***

— җитәкченең нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә;
— эш көнен планлаштыруга ярдәм итәргә;
— җитәкченең эш урынын оештырырга;
— вакытны контрольдә тотарга;
— җитәкчегә мәгълүмати хезмәт күрсәтүне оештырырга;
— көндәлек матбугат белән эшләргә (кыскача мәгълүмат бирергә);
— килүчеләрне кабул итүне оештырырга;
— элемтә, хәбәрдарлык урнаштырырга;
— киңәшмә эшен оештырырга һәм тәэмин итәргә;
— шәхси компьютер ярдәме белән документлар төзергә һәм аларны тиешенчә тутырырга;
— документларны тиз арада күбәйтергә;
— элемтә (факс, электрон почта) ярдәме белән ашыгыч мәгълүмат тапшыруны тәэмин итәргә;

— документлар белән түбәндәге эшләрне алып барырга: кабул итәргә, җибәрергә, башлангыч эшкәртергә, бүләргә, теркәргә, тикшереп торырга, документ буенча мәгълүмат-белешмә эшен алып барырга, сакларга, юкка чыгарырга;
— архивны алып барырга.

## Сәркатиплек хезмәтенең һөнәри этикасы

Сәркатиплек хезмәтенең һөнәри этикасы түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

***Тышкы кыяфәткә таләпләр:***

— купшы булмаган гади матур костюм;
— дөрес сайланган аксессуар;
— прическа белән костюмның бөтенлеге;
— косметиканы чама белеп куллану.

***Сәркатипнең эш урыны культурасы***

Кабул итү бүлмәсенең тышкы күренеше өчен сәркатип җаваплы була. Барыннан да элек:
— җиһазларны уңайлы урнаштырырга һәм кабул итү бүлмәсен дөрес бизәргә;
— мебельне сак тотарга, санитар торышын даими тикшереп торырга;
— тәкъдим ителүче үзгәрешләрнең зарурлыгына һәм уңайлылыгына җитәкчене ышандырырга.

***Сәркатипнең үз-үзен тоту һәм аралашу культурасы***

Сәркатипнең югары культуралылыгын раслаучы сыйфатлар: ягымлылык, әдәплелек, ихтирамлылык, игелеклелек.

Сәркатип һөнәре кешеләр белән инсафлы булуны таләп итә.

Үз-үзеңне дөрес тота белү — эштәге уңышның төп шарты.

Сәркатипнең түбән культуралы булуын күрсәтә торган сыйфатлар:
— усал караш, караңгы йөз, зәһәр ирония;
— масаю яисә битарафлык.

Җитәкче белән сәркатипнең дөрес мөгамәләсе уртак эшнең уңышы өчен төп шарт булып тора.

Сәркатип — җитәкченең эшен шәхси оештыручы, ул:
— җитәкчегә күз алдында тотылган чараларны үтәргә булыша;
— телефон аша хәбәрләшүне җайга сала.

Яхшы сәркатип җитәкчегә карата чамасын белеп игътибарлы була һәм кайгыртучанлык күрсәтә.

## Сәркатипнең эшлекле һәм шәхси сыйфатлары

Сәркатип һөнәре әлеге хезмәткә бәйле үзенчәлекләргә ия булган югары әзерлек, тиешенчә шәхси һәм эшлекле сыйфатлар таләп итә.

Сәркатип эше беренче карашка гади, артык белем таләп итми торган җиңел эш булып күренергә мөмкин, ә чынлыкта исә әлеге һөнәр хезмәт күрсәтү өлкәсендәге җаваплы профессияләрнең берсе булып тора.

Сәркатип эш дәвамында кешеләр белән аралаша, һәм аңа түбәндәге эшлекле сыйфатларга ия булырга кирәк:

— һөнәри осталык;
— инициативлылык;
— оешканлык;
— җаваплылык;
— төгәллек;
— хәбәрдарлык;
— дипломат булу;
— яхшы хәтергә ия булу;
— хезмәт серен саклый белү;
— эшкә бирелгәнлек.

Эшлекле сыйфатлар белән бергә түбәндәге шәхси сыйфатларны да булдыру кирәк:

— зыялылык;
— эш сөючәнлек;
— намуслылык;
— ярдәмчел булу һәм яраклаша белү;
— тыйнаклык;
— пөхтәлек;
— игелеклелек.

Югарыда телгә алынган эшлекле һәм шәхси сыйфатлар кешегә әзер рәвештә бирелми. Сайлаган һөнәреңдә уңышларга ирешү өчен, акыл белән, чын күңелеңне биреп, ныклы әзерлек үтеп һәм җаваплылык хисе тоеп эшләү зарур.

## Хезмәт этикеты

**Хезмәт этикеты** — җитештерү, хезмәт күрсәтү, фән, мәдәният өлкәсендә һ.б. күп кенә өлкәләрдә үз-үзеңне тоту, әхлак кагыйдәләре җыелмасы ул.

Этикет саклау һәр эшнең урынына, вакытына һәм төрле вазгыятьләргә бәйле. Этикет кагыйдәләре башлыча шартлы характерда була, ул — һәркемнең эчке культурасы чагылышы. Аларны белү һәм дөрес куллану үзара эшчәнлектә уңышларга ирешү өчен зур әһәмияткә ия. Эшлекле даирәдә этикет кагыйдәләре җиренә җиткерелеп үтәлергә тиеш.

Һәр кабул итүгә алдан ук әзерләнергә кирәк. Аңа түбәндәгеләр керә:

— кабул итүнең төре:
— фуршет;
— коктейль;
— төшке аш (урыннар белән);
— төшке аш-буфет;
— кичке аш (урыннар белән);
— чакырылучы затларның исемлеген төзү (чакыру кәгазьләрен әзерләү һәм аларны тапшыру — сәркатип вазифасы);
— чакыру кәгазьләрен тиешле адресларга җибәрү;
— кунакларны өстәл янына утырту планын төзү;
— меню төзү;
— өстәлләрне сервировкалау (Ашъяулык тигез ятсын һәм шуып йөрмәсен өчен, өстәлгә башта фланель җәелә. Һәр прибор астына салфетка куела. Төшке һәм кичке ашлар өчен өстәлне сервировкалауның берничә төре бар);
— кунакларны кабул итүнең сценариен төзү.

**Өстәл этикеты.** Өстәл янында үз-үзеңне тотуның төп кагыйдәсе — мөмкин кадәр тыныч һәм тавыш чыгармыйча ашау-эчү.

Өстәл янында тәмәке тарту рөхсәт ителми. Тәмәке тартучылардан гына торган компания җыелган очракта гына мөмкин.

Соңгы вакытта эшлекле даирәләрдә партнерлар җәлеп итү өчен тәкъдим итүләр уздыру киң таралды. Алдан ук аны үткәрү урыны билгеләнә, сценарий әзерләнә. Тәкъдим итү күбесенчә төштән соң үткәрелә. Бинаны реклама плакатлары, стендлар белән бизиләр. Тәкъдим итүдә катнашучыларга истәлекле сувенирлар (реклама бүләкләре) тапшырыла.

Бүләкне сайлаганда, аның кемгә тапшырылачагын күз алдында тотарга кирәк. Бер үк кешегә бер үк төрле бүләк кабатланмаска тиеш (бу — спиртлы эчемлекләргә кагылмый).

### СӘРКАТИПНЕҢ ДОКУМЕНТЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮДӘН ТЫШ ХЕЗМӘТЕ

Документлар белән эшләүдән, машинка яки компьютерда эш башкарудан тыш, сәркатип җитәкчесе, хезмәттәшләре, офиска килүчеләр белән турыдан-туры һәм телефон, факс, почта элемтәсе аша читтән торып һәрдаим аралашып тора. Мондый эшләргә эш көненең кимендә 60 проценты сарыф

ителә. Аралашуның һәр төре үзенә генә хас үзенчәлеккә ия. Бу үзенчәлекләрне белү — эш вакытын төгәл файдалану һәм һөнәри вазифаларны тиешенчә үтәү өчен гаять әһәмиятле.

Сәркатип җитәкченең беренче ярдәмчесе булганга, аның вазифасына эшне оештыру һәм мәгълүматлар белән тәэмин итү эшчәнлеге дә керә. Сәркатип җитәкче белән идеаль мөнәсәбәтләр булдыру өчен кирәкле сыйфатларга да ия булырга тиеш. Бу сыйфатлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— бер генә эш кәгазендә, документта да хата җибәрмәү һәм мөстәкыйль рәвештә эш башкара белү;
— телефоннан сөйләшкәндә теләсә нинди сорауга да әдәпле җавап бирү;
— хисаплардан һәм журналлардан иң мөһим фактларны сайлап ала белү;
— ашыгыч эшләр булганда эштән соң калып эшләү кирәклеген аңлый белү;
— җитәкчесе югында мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл иткәндә, үз вазифаларын һәм вәкаләтлелек дәрәҗәсен төгәл белү;
— җитәкчесенең шәхси тормышындагы вакыйгалар, хәлләрдән хәбәрдар булып, аларны күз уңыннан җибәрмәү.

Яхшы сәркатип җитәкчесенә әдәплелек кысаларында игътибарлы булуны һәм аның турында артыгын җибәрмичә кайгыртуны үзенең бәхәссез бурычы дип саный. Үзара аңлашуга ирешелгән очракта, җитәкче үз сәркатибенә кайбер мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итүне дә тапшырырга мөмкин.

Сәркатип җитәкченең ярдәмчесе икән, ул коллективта эшлекле уңай мөнәсәбәтләр булдыру өчен бөтен көчен куярга тиеш.

Йомыш белән килүчеләрне кабул итү эшләрен планлаштырганда, җитәкченең шәхси мәсьәләләр буенча никадәр еш, кайсы көннәрдә һәм кайсы сәгатьтә кабул итү мөмкинлеге булу исәпкә алына.

Йомыш белән килүчеләрне кабул итү нигездә түбәндәгечә башкарыла: җитәкчегә керергә теләүчеләр алдан языла һәм, билгеләнгән көне, тәгаенләнгән сәгатендә килгәч, кабул итү кенәгәсенә тиешле язма теркәлә.

Сәркатип шуны да истә тотарга тиеш: йомыш белән килгән һәр кеше, дәрәҗәсенә карамастан, җитәкче бүлмәсенә бары тик сәркатип аның килүен хәбәр иткәннән соң гына керә ала.

Сәркатип, йомыш белән килүчене теге яки бу мәсьәләне хәл итү өчен вәкаләтле хезмәткәргә юллау максатында, учреждениенең җитәкче хезмәткәрләре арасында вазифаларның һәм мәсьәләләрнең бүленешен яхшы белергә тиеш.

Әңгәмә беткәннән һәм карар кабул иткәннән соң, җитәкче сәркатипкә тиешле исәпкә алу формаларында әңгәмә нәтиҗәләре турында язып куюны йөкли.

Җитәкче кабул иткән карарларның үтәлешен тикшерүне сәркатип башкара. Ул тәмамланмаган һәм каралырга тиешле эшләрне үзендә саклый һәм аларны әлеге мәсьәлә буенча кабат кабул итү вакытына җитәкчегә әзерли.

## Эшлекле әңгәмә алып бару кагыйдәләре

Көндәлек эшендә сәркатипкә җитәкче, йомыш белән килүче, хезмәттәшләре белән һәм телефон аша эшлекле әңгәмә алып барырга туры килә.

Эшлекле әңгәмә берничә төп этаптан тора:
— мәсьәлә белән танышу һәм аны бәян итү;
— билгеле бер карарга килүгә тәэсир итүче факторларны тәгаенләү;
— карарны сайлап алу;
— карарны кабул итү һәм аны әңгәмәдәшкә җиткерү.

Эшлекле әңгәмәне уңышлы төгәлләү өчен, сәркатип:
— вәкаләтле булырга;
— әдәпле булырга;
— дустанә булырга;
— әңгәмә алымнарын үзләштергән булырга;
— әңгәмәдәшенә сораулар бирә һәм аны тыңлый белергә тиеш.

## Телефон аша сөйләшүләр алып бару

Югары белгечлеккә ия сәркатип телефон аша хезмәти сөйләшүләр алып бару кагыйдәләрен үзенең көндәлек эшлекле аралашу нормасы булырлык дәрәҗәдә үзләштерергә тиеш. Телефон аша сөйләшүләр алып барганда, түбәндәге кагыйдәләрне үтәү шарт:

— барлык телефон шалтырауларына да җавап бирегез;
— трубканы алгач, иң элек үзегез белән таныштырыгыз;
— тискәре хисләрегезне, мөнәсәбәтегезне белдерүдән тыелып калыгыз;
— кычкырып сөйләмәгез: тавышны боза;
— трубканы авыздан 1,5 см ераклыкта тотып, туп-туры микрофонга сөйләгез;
— сүзләрне ачык итеп, ашыкмыйча әйтегез, ашыгып сөйләгәндә сөйләү кимчелекләре тагын да калкурак күренә;
— хәбәр итәргә җыенган мәгълүматларның төгәллегенә, дөреслегенә иманыгыз камил булсын;
— урынында туры килмәгән кешегә тапшырылган мәгълүматның иясенә барып җитүенә ярдәм итегез.

Эшлекле сөйләшү вакытында туганнарыгыз һәм якыннарыгызның сәламәтлеге, һава торышы һәм башкалар турында сүз алып барылырга тиеш түгел.

Телефон аша бирелгән җаваптан әбүнәчедә әлеге учреждение турында гына түгел, җавап бирүченең үзе турында да билгеле бер фикер туарга мөмкин. Бу фикер тискәре булмасын өчен, тупас җаваплардан, усал тоннан качарга кирәк.

Белешмәләр бирү өчен сәркатипкә үз учреждениесе телефоннары исемлеген, шәһәр телефоннары кенәгәсен булдырырга кирәк.

Телефон шалтырагач та, сәркатипкә нәрсә эшләргә, нәрсә эшләмәскә кирәклеге түбәндә тәкъдим ителә:

***ярамый:***

1. Трубканы озак алмый торырга;
2. Сөйләшә башлагач, «сәлам», «әйе», «сөйләгез» дип әйтергә;
3. «Сезгә ничек ярдәм итә алам?» — дип сорарга;
4. Берьюлы ике телефоннан сөйләшергә;
5. Аз вакытка гына булса да телефонны кешесез калдырырга;
6. Мәгълүматны кәгазь кисәкләренә, аерым битләргә язарга;
7. Трубканы күп мәртәбәләр әле бер кешегә, әле икенчесенә бирергә;
8. «Беркем юк, бар да төшке ашта, соңрак шалтыратыгыз, зинһар», — дияргә.

***кирәк:***

1. Телефон 4 тапкыр шалтыраганчы, трубканы алырга;
2. Хәерле иртә (көн) теләргә, кемлегеңне белдерергә, бүлегеңне атарга;
3. «Сезгә ярдәм итә аламмы?» — дип сорарга;
4. Сөйләшү эчтәлеген игътибар белән тыңларга;
5. Кайбер нәрсәләрне ачыклау кирәк булганда, кабат шалтыратуны тәкъдим итәргә;
6. Телефоннан сөйләшүләрне язып бару өчен махсус бланклардан файдаланырга;
7. Шалтыратучының телефон номерын язып алырга һәм аңа кабат шалтыратырга;
8. Мәгълүматны язып алырга һәм әбүнәчегә кабат шалтыратачагын әйтергә.

## Утырышлар һәм киңәшмәләр уздыру

Җыелып тикшерүне таләп итүче мәсьәләләрне хәл итү өчен киңәшмәләр уздырыла. Атна саен, ай саен уздырыла торган һәм диспетчер киңәшмәләре була.

Утырышларны, киңәшмәләрне дөрес итеп үткәрү өчен яхшы әзерлек таләп ителә. Эшне планлаштырган вакытта ук, җитәкче белән сәркатип кайчан һәм нинди киңәшмәләр үткәреләчәген алдан билгелиләр, аның темасын, катнашучылар составын, үткәрү урынын тәгаенлиләр.

Җитәкче киңәшмәгә чакырылган очракта, сәркатип тиешле документларны әзерләп куярга, доклад текстын басарга, киңәшмәне уздыру көне, сәгате һәм урыны турында җитәкченең исенә төшерергә тиеш.

Зур булмаган ашыгыч киңәшмәләр үткәргәндә җитәкченең алыштыргысыз ярдәмчесе булганга, сәркатип вазифасына түбәндәгеләр өстәлә:

— киңәшмәдә катнашучыларга бу турыда хәбәр итү һәм аларның киңәшмәгә килүен тикшерүдә тоту;
— киңәшмә вакытында телефоннан җавап бирү һәм килгән кешеләрне кабул итү; киңәшмәдә катнашучылар өчен эш урыннары һәм язу өчен кәгазь булуын тикшерү;
— кирәк булган очракта, медицина ярдәме күрсәтү.

Киңәшмәгә әзерлек атна ярым-ике атна кала башлана. Сәркатип, җитәкчесе белән, телефонограмма тексты, чакырулар яза һәм, заказ белән җибәрелгән хат итеп, киңәшмәдә катнашучыларга тарата.

Чакыру текстына учреждениенең исеме, киңәшмәнең асылы, үткәрү вакыты һәм урыны, чакырылучының фамилиясе һәм инициаллары языла.

Киңәшмәгә 4—5 көн кала, сәркатип катнашучылар исемлеген тикшерә һәм докладны компьютерда (машинкада) җыя. Киңәшмәне үткәрү өчен бина (бүлмә) билгеләнгәч, сәркатип учреждениенең тиешле хезмәткәрләрен бүлмәне җиһазлауга җәлеп итә, транспортка заказ бирә.

Катнашучыларны теркәү киңәшмәгә 30 минут кала башлана, һәм, кагыйдә буларак, ул киңәшмә уздырыла торган бүлмә алдында үткәрелә.

Киңәшмә барышында сәркатипкә беркетмә язу йөкләнергә мөмкин. Киңәшмә узгач, бүлмә элекке тәртибенә китерелә.

## КОММЕРЦИЯ СЕРЕ

Предприятие, оешма өчен коммерция сәбәпләре буенча фактик һәм потенциаль кыйммәте булган эшлекле мәгълүмат коммерция серен тәшкил итә. Коммерция сере идарә итү, җитештерү, фән-техника, сәүдә өлкәсенә караган мәгълүматны махсус документларда саклау рәвешендә чагылдырыла.

Коммерция серен тәшкил итүче мәгълүматның төгәл исемлеге җитәкче тарафыннан билгеләнә. Түбәндәге мәгълүматлар коммерция сере булырга мөмкин.

Җитештерү өлкәсендә:

— кадрлар структурасы;
— җитештерүнең характеры;
— предприятиенең үсеш планнары;
— предприятиенең җитештерү мөмкинлекләре турында мәгълүматлар.

Продукцияне реализацияләү өлкәсендә:

— базарны өйрәнүнең үзенчәлекле ысуллары;
— маркетинг тикшеренүләренең нәтиҗәләре;
— базар стратегиясе;
— товарларның базарга чыгу вакыты;
— тәэмин итүчеләр һәм кулланучылар;
— бәяләрне исәпләү ысулы турындагы мәгълүматлар.

Сөйләшүләр алып барганда:

— алына торган заказлар һәм тәкъдимнәр турында;
— сөйләшүләрне әзерләү һәм алып бару фактлары турында;
— сөйләшүдә катнашучылар, предприятие җитәкчелеге, аларга тасвирнамә бирү турындагы мәгълүматлар.

Түбәндәгеләр коммерция серен тәшкил итмиләр:

— гамәлгә кую документлары һәм Устав;
— эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукы бирә торган документлар;
— түләүне гамәлгә ашыру документлары;
— эшләүчеләрнең саны, составы, хезмәт хакы, эш шартлары турында белешмәләр;
— салымнарны һәм мәҗбүри түләүләрне күчерү турындагы белешмәләр;
— әйләнә-тирә мохитне зарарлау, монополиягә каршы законнарны бозу турында белешмәләр.

## Мәгълүматны читкә тарату каналлары

Мәгълүмат тышкы һәм эчке каналлар аша читкә таратылырга мөмкин.

**Тышкы канал** — намуссыз хезмәткәрләрнең яисә җинаятьчеләрнең турыдан-туры эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Аларга түбәндәгеләр керә:

— тыңлау җайланмалары ярдәмендә мәгълүмат алу;
— документларны урлау яисә күчермәләрен алу;
— мәгълүматны юкка чыгару яисә аның чыганакларына зыян китерү;
— предприятие хезмәткәрләрен ришвәт белән кызыксындыру;
— шантаж белән куркыту;
— төп белгечләрне үз ягына димләү.

**Эчке канал** — хезмәт хакыннан риза булмау яисә җитәкче белән мөнәсәбәтләрнең канәгатьләндермәве аркасында, кайбер хезмәткәрләрнең үчләшүенә һәм намуссызлыгына бәйле. Сөйләшүләр алып барган хезмәткәрләрнең сер саклый белмичә артык күп сөйләүләре шулай ук эчке канал чыганагы булып тора.

## Коммерция серен саклау ысуллары

Коммерция серен саклау өчен түбәндәге чаралар файдаланыла:

— хокукый яклау;
— оештыру чаралары;
— территорияне, элемтә, компьютер системасын һәм белешмәләр базасын саклауны үз эченә алган техник чаралар.

### ДОКУМЕНТЛАРНЫ ТӨЗҮГӘ ҺӘМ ТУТЫРУГА ТАЛӘПЛӘР

Идарә итү эшендә һәр карар тикшерелә торган объект яисә карала торган мәсьәлә турындагы мәгълүматка нигезләнә. Мәгълүматка төп ике таләп куела: беренчедән, ул үз вакытында, икенчедән, иң төгәл карар кабул итәр өчен җитәрлек булырга тиеш. Хәзерге вакытта мәгълүмат күләме һәр өч ел саен бермә-бер арта бара. Җәмгыять мәгълүмат ташкыны чорында яши. Бу, барыннан да элек, халык саны артуга бәйле. Теләсә кайсы оешма өчен мәгълүмат алмашу бик мөһим. Мәгълүматка ия булып кына вазгыятьне җитәрлек белергә мөмкин. Ә документ мәгълүмат чыганагы булып тора. Шунлыктан, документ белән эшләүгә гаять зур игътибар бирелә.

Документлар яшәешнең, эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә файдаланыла һәм күп кенә фәнни дисциплиналарның тикшерү объекты булып тора. «Документ» төшенчәсе күпкырлы, һәм аның эчтәлеге нинди максатларда файдаланылуына бәйле.

Документ мәгълүматны терки, аның сакланышын һәм тупланышын, башка затка тапшырылу мөмкинлеген һәм күп тапкырлар файдаланылышын тәэмин итә.

Документ законлылыкны һәм контрольне ныгытуның бер алымы да. Документацияне тәртипкә китерүнең төп юнәлешләре бердәйләштерү һәм стандартлаштырудан гыйбарәт.

Бердәйләштерү дигәндә нәрсәне дә булса бердәм системага, формага, рәвешкә китерү аңлашыла.

Стандартлаштыру — стандартларны билгеләү һәм куллану гамәле, ул исә башка шундый объектлар белән чагыштырып караганнан соң кабул ителә торган үрнәк, эталон, модель.

Документларның бердәйләштерелгән системасы — билгеле бер эшчәнлек өлкәсендә идарә итү өчен кирәкле мәгълүматны туплаган бердәм кагыйдәләр һәм таләпләр буенча төзелгән документлар системасы.

Сәркатип, барыннан да элек, оештыру-боеру системасындагы документлар белән эш итә. Кечкенә фирмаларда сәркатип башлангыч исәпкә алу документлары системасы, финанс һәм бухгалтерлык документлары белән дә эшли.

## Оештыру-боеру документларының (ОБД)

**үрнәк формасын төзү**

Эш башкаруны камилләштерү өчен түбәндәгеләрне белү зарур:
— документлар белән эшләүне гадиләштерү;
— документ төзүне тизләтү;
— документны дөрес тутыру.

Моның өчен оештыру-боеру документларының бердәйләштерелгән системасы ГОСТ Р 6.30—97 стандартының «Документларны тутыруга таләпләр» бүлеге ярдәмгә килә. Әлеге ГОСТ документларны тулысынча бердәйләштерергә мөмкин- лек бирә.

Стандарт — документларны төзү һәм машинкада басуның кайбер реквизитлары гомуми кагыйдәләрен билгели.

ГОСТ Р 6.30—97 дәүләт хакимиятенең үзәк һәм җирле органнарының боеру, башкарма эшчәнлеген рәсмиләштергәндә кулланыла һәм документларны тутыруга, урнаштыруга, шулай ук үрнәк форманың реквизитлары саклануга гомуми таләпләрне билгели. Документның үрнәк формасы — аның даими һәм алмашынып торучы төрле реквизитларын урнаштыру мәйданы, реквизитның озынлыгы төгәл билгеләнгән бердәйләштерелгән форма моделе.

Даими реквизит — документны әзерләгәндә күрсәтелүче реквизит.

Алмаш реквизит — документны тутырганда күрсәтелүче реквизит.

ГОСТ Р 6.30—97 ике кәгазь форматы белән билгеләнә: А4 (210ә297 мм) һәм А5 (148ә210 мм). Һәр формат өчен реквизитларны урнаштыруның ике варианты мәгълүм. Беренчесе — реквизитлар почмакка куела; икенчесе — буйга (бит буенча) урнаштырыла.

Стандарт үрнәк формасы кырларының түбәндәге үлчәмнәрен (кимендә һәм миллиметрларда) билгели:

— сулъяк кыр — 20 (эшләрне тегү һәм төпләү өчен);
— уңъяк кыр — 10 (текстны саклау өчен);
— өске кыр — 20 (кәгазь битенең өске читеннән үлчәнә);
— аскы кыр (А4 үлчәмле кәгазь бите өчен) — 10.

## Документларның реквизитлары составы

Документларны тутыруда бердәй таләпләр һәм кагыйдәләр бар. Документның һәр төренә (боерык, хат, акт) билгеле бер реквизит җыелмасы хас. Документларның аеруча мөһим реквизитлары:

01 — Россия Федерациясенең Дәүләт гербы;
02 — Россия Федерациясе субъекты гербы;
03 — оешманың эмблемасы;
04 — оешманың коды;
05 — документ формасының коды;
06 — оешманың исеме;
07 — оешма турында белешмә мәгълүматлар;
08 — документ төренең исеме;
09 — документның датасы;
10 — документның теркәлү номеры;
11 — документның теркәлү номерына һәм датасына сылтама;
12 — документ төзелгән һәм басылган урын;
13 — документ белән файдалану мөмкинлеген чикләү грифы;
14 — адресат;
15 — документны раслау грифы;
16 — резолюция;
17 — текстка баш исем;
18 — контроль турында билге;
19 — текст;
20 — кушымтаның барлыгы турында билге;
21 — имза;

22 — документның килештерелүе турында гриф;
23 — документның килештерелүе турында имза;
24 — мөһер;
25 — күчермәне раслау турында билге;
26 — башкаручы турында билге;
27 — документның үтәлгәнлеге турында билге;
28 — документның оешмага керүе турында билге;
29 — документны автомат рәвештә эзләү өчен билге.

Һәрбер документны төп өч өлешкә бүләргә мөмкин:
— документның башы;
— төп өлеше;
— рәсмиләштерә торган өлеше.

Теләсә кайсы документны әзерләгәндә (01—07 реквизитлардан гайре) УСОРД (ОБДУС) нигезендә документ төренең исеме куела (хатлар моңа карамый).

Документка кул кую һәм раслау көне документның датасы була, беркетмә өчен — утырыш уздырылган көн, акт өчен — вакыйга булган көн. Әгәр документ берничә оешма тарафыннан язылса, документка соңгы кул куелган көн документ датасы була. Датаны куюның сүзле сан белән күрсәтү рәвеше дә була, мәсәлән:

1999 елның 20 октябре.

Башка оешмага җибәрү өчен әзерләнгән документның теркәү саны булырга тиеш, бу сан эшләр исемлеге буенча үз индексы белән тулыландырыла ала.

Документның адресаты булып оешмалар, аларның структур бүлекчәләре, урындагы һәм физик затлар тора ала. Оешма һәм аның структур бүлекчәләре баш килештә күрсәтелә.

Мәсәлән:

Татарстан Республикасының Мәгариф министрлыгы

Башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләренең республика берләшмәсе

Документ адресланган затның вазифаи исемен шулай ук баш килештә язалар.

Мәсәлән:

68нче һөнәр училищесы
Директор
Ә.Н.Садыйковка

яки

68нче һөнәр училищесы
директоры
Ә.Н.Садыйковка

Документ берничә бердәй оешмага яки бер оешманың берничә структур бүлекчәсенә җибәрелгәндә, аларны берләштереп язарга кирәк, мәсәлән:

Татарстан Республикасының
һөнәр лицейларына

«Адресат» реквизиты составында, кирәк булганда, почта адресы да күрсәтелергә мөмкин. Адрес элементларын Почта кагыйдәләрендә билгеләнгән эзлеклелектә язалар.

Документта иң күбе дүрт адресат булырга тиеш. Икенче, өченче һәм дүртенче адресатлар алдына «Күчермә» сүзе язылмый. Адресатлар саны күбәеп киткәндә, документка аларның исемлеге теркәлә.

Әгәр хат оешмага юлланса, бу оешманың исемен, почта адресын күрсәтергә кирәк, мәсәлән:

68нче һөнәр училищесы
420103, Казан шәһәре,
Әмирхан урамы, 12нче йорт

Документны физик затка юллаганда, әүвәл почта адресын, аннан соң адресатның инициалларын һәм фамилиясен язалар, мәсәлән:

420031, Казан шәһәре,
Пионерская урамы,
65нче йорт, 6нчы квартир
А.М.Калининга

Урындагы зат (затлар) документны раслаганда, раслау грифы РАСЛЫЙМ дигән сүздән (куштырнакларсыз), документны раслаучының вазифаи исеме, имзасы, инициаллары һәм фамилиясеннән тора, иң соңыннан дата куела, мәсәлән:

РАСЛЫЙМ
Казанның «Заря» кондитер фабрикасы» акционерлар җәмгыяте генераль директоры
Шәхси имза И.И.Сергеев
12.10.99

Документ урындагы берничә кеше тарафыннан имзаланса, аларның имзалары бер үк тигезлектә урнаштырыла.

Документны карар, боерык, беркетмә белән раслаганда, раслау грифы РАСЛАНГАН дигән сүздән (куштырнакларсыз), документны раслаучы оешманың иялек килештәге исеменнән, раслау көненнән һәм санынннан, раслаучы документның баш килештәге III зат тартымлы исеменнән тора, мәсәлән:

РАСЛАНГАН
Акционерлар гомуми
җыелышының 1999 ел,
17 октябрь, 23нче карары

яки

РАСЛАНГАН
КМПО акционерлар җәмгыяте
директоры урынбасарының
1999 ел, 5 ноябрь, 78нче боерыгы

## Документ текстына таләпләр

Текст — документның эчтәлеген ачучы һәм документны расмиләштерүче төп реквизит. ГОСТ Р6.30—97 буенча документ текстның нинди телдә язылуы күрсәтелеп башланырга тиеш. Документ Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт телләре турындагы закон-нары нигезендә рус телендә дә, татар телендә дә төзелергә мөмкин. ГОСТ белән, шулай ук, документ текстының бары тик рус телендә генә тутырылган очраклары да билгеләнә.

Документны төзегәнче:

— документның максатын, максатка ярашлылыгын, хәл ителәсе мәсьәләләрнең даирәсен ачыкларга;
— закон чыгару актларын, хөкүмәт карарларын, ведомстволарның норматив актларын өйрәнергә кирәк.

Боеру документларын төзегәндә, бу өлкәдә элек басылган документлар өйрәнелә. Документлар кабатланмаска тиеш. Сүзләр сайлауга җитди әһәмият бирелә. Бер җөмләдә тамырдаш сүзләр кулланылмаска, ягъни тавтология күренеше булмаска тиеш.

Эш документлары нейтраль тон белән аерылып тора. Язма өченче зат исеменнән алып барыла, алмашлыклар урынына исемнәр языла.

Документның тексты бер яисә берничә гыйбарәдән торган абзацларга бүленә. Яңа фикер яңа абзацтан башлана. Әлеге алым документның эчтәлеген аңларга, укыганда пауза ясарга мөмкинлек бирә. ГОСТ буенча абзац 5 басма билге сыярлык урын калдырып башлана.

Катлаулы һәм зур күләмле текстлар түбәндәге өлешләргә бүленә: бүлекләр, бүлекчәләр, пунктлар, пунктчалар. Алар гарәп цифрлары белән күрсәтелә.

Идарә итү документының бердәйләштерелгән тексты трафарет, анкета, таблица рәвешендә бирелергә мөмкин.

Бердәйләштерелгән даими мәгълүмат белән һәм, әлеге документта чагылдырыла торган конкрет тәгаенләнгән вазгыятьне тасвирлаучы яңа мәгълүматны язу өчен аралар калдырып, алдан ук басылган текст трафарет дип атала.

Күп сандагы адресатларга бер типтагы хатлар җибәргәндә, трафарет текстларны куллану бик уңай.

Трафарет текстларыннан тыш, хәбәрләшүдә стандарт гыйбарә һәм фразаларны куллану киң чагылыш тапты.

Түбәндәге гыйбарәләр күп кулланыла:

— Хөрмәтле ...;
— Кадерле ...;
— Хатыгызны алдык, рәхмәт ...;
— Килеп чыккан (булган) мөмкинлектән файдаланып, ...;
— Сезнең тәкъдимнәрегезне өйрәндек ...;
— Хатыгызга җавап җибәрәбез ...;
— Үтенечегезне канәгатьләндерәбез ...;
— Үтенечегезне канәгатьләндерә алмыйбыз ...;
— Тоткарлык өчен гафу үтенәбез ...;
— Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Сезгә ...;
— Җавап килмәгән очракта ...;
— Сезнең игътибарыгызны ... юнәлтүгә ...;
— Кирәк дип саныйбыз ...;
— Ихтирам белән ...;
— Уңышлар, бәхет теләп, ... .

## Документ текстының баш исеме

Документның текстын тәмамлаганнан соң, текстның баш исеме бирелә. Ул теләсә кайсы документның мәҗбүри атрибуты булып тора, ачык, кыска һәм төгәл языла. Анда документның төп эчтәлеге чагыла. Текстның баш исеме «кем яисә нәрсә турында?» дигән сорауга җавап бирә, мәсәлән:

Аттестация комиссиясе төзү турында
БОЕРЫК;

яки «кемнең?», «нәрсәнең?» дигән сорауларга җавап бирә, мәсәлән:

Сәркатипнең вазифаи тәгълимнамәсе.

Баш исемне документны әзерләүче билгели. Ул бланкның төп реквизитлары астында өске якның сул почмагында урнаштырыла һәм документны эшкәртү эшен шактый җиңеләйтә. Текстның баш исеме документны теркәүне, эш кәгазьләре арасында аны эзләп табуны, контрольдә тотуны җайга салырга мөмкинлек бирә.

А5 (148ә210 мм) форматлы кәгазьдә башкарылган кыска документларны (хәбәрнамә, телеграмма) гына баш исемне куймыйча язу рөхсәт ителә.

Баш исемне билгеләү — документларны дөрес тутыруга куелган мөһим таләпләрнең берсе.

## Эш документлары текстларын килештерү

Эш документлары текстларын килештерү — документ проектын алдан карау һәм бәяләү алымы.

Документ проектын килештерү әзерләнгән документның сыйфаты, аның максаты турындагы мәсьәләне дөрес һәм һәрьяклап хәл итүне тәэмин итәргә тиеш.

Документ проектлары хәл ителәсе мәсьәләләргә турыдан-туры катнашы булган оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр, структур бүлекчәләр һәм урындагы затлар белән килештерелергә тиеш.

Оештыру-боеру документлары белән эш иткәндә, килештерү ике төрле: эчке һәм тышкы булырга мөмкин.

**Эчке килештерү** төрле бүлекчәләр һәм урындагы затлар тарафыннан башкарыла, проектка имза салып рәсмиләштерелә. Имза янына дата да куела. Эчке документларда визаны беренче нөсхәнең

соңгы битенә «Имза» реквизиты янына, сул якта калган ара чигеннән башлап куялар. Җибәрелүче документларның оешмада яисә структур бүлекчәдә кала торганнары имзалана.

**Тышкы килештерү** буйсынучы һәм буйсынмаучы оешмаларга кагыла. Килештерү турында гриф белешмә яисә документ проекты буенча коллегиаль орган утырышларында фикер алышканнан соң төзелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә. Грифта КИЛЕШТЕРЕЛДЕ дигән сүз, урындагы затның биләгән эш урыны, шәхси имзасы, тулысынча исем-фамилиясе һәм килешенү датасы куела. КИЛЕШТЕРЕЛДЕ сүзе куштырнаксыз һәм ике ноктасыз языла. Әгәр берничә гриф куярга кирәк булса, алар вертикаль рәт итеп урнаштырыла.

## Документларны таныклау

Документларны таныклау — аның эчтәлеге һәм законлылыгы өчен җаваплылыкны белдерү рәвеше. Төп таныклау алымнары имзалау, раслау, мөһер сугудан гыйбарәт.

**Имзалау** (кул кую) — документның мәҗбүри реквизиты. Документка учреждениенең җитәкче хезмәткәрләре имза сала. Реквизит составына түбәндәгеләр керә:

— документка имза салучы урындагы затның биләгән эш урыны, аның фамилиясе һәм инициаллары;
— шәхси имза.

Документның беренче нөсхәсе имзалана. Документ бланкта язылмаган булса, реквизитка оешманың атамасы да керә. Документ өчен берничә зат җаваплы булса, аларның һәрберсе имза сала. Имзалар вертикаль рәвештә, 2 интервал аша куела. Әгәр документка бер үк дәрәҗәдәге берничә урындагы зат кул куярга тиеш булса, имзалар бер тигезлектә, горизонталь рәвештә урнаша.

**Раслау** — документ имзаланганнан соң аны таныклауның мөһим алымы. Реквизит РАСЛЫЙМ дигән сүздән, документны раслаучы урындагы затның биләгән эш урынының тулы атамасыннан, шәхси имзасыннан, фамилиясе белән инициалларыннан һәм раслау датасыннан тора (2нче кушымтаны кара).

Аеруча таныклауны таләп иткән документларга **мөһер сугыла**. Мөһернең бер өлеше документка кул куйган урындагы затның биләгән эш урыны атамасы язылган сүз өстенә туры килергә тиеш. Документларга герблы мөһер дә куела. Андый документлар исемлеге норматив актлар нигезендә билгеләнә (3нче кушымтаны кара). Күчермәләргә гади мөһер сугыла. Учреждение бланкларындагы эш хатлары мөһер белән таныкланмый.

Документ күчермәсенең төп нөсхәсенә туры килүен таныклаганда, «Имза» реквизитыннан аска түбәндәгеләрне язалар: «Дөрес» дип таныклау; күчермәне таныклаучы затның вазифасы, шәхси имза, имзаны ачу (инициаллар һәм фамилия), таныкланган көн, мәсәлән:

Дөрес:
Кадрлар бүлеге инспекторы Шәхси имза Ә.М.Хөсәенов
09.04.99

Документ күчермәсе оешма үзе кирәк дип тапкан мөһер белән таныкланырга мөмкин.

## Документларда махсус билгеләр

**Кушымта** — нинди дә булса документка өстәмә, ул 3 төргә бүленә:

— тиешле боеру документлары белән расланучы яисә гамәлгә кертелүче кушымталар (хокукый актларга кушымталар);
— төп документның эчтәлеген аңлатучы яисә аңа өстәмә кертүче кушымталар;
— иярчен хат белән җибәрелүче кушымталар.

**Искәрмә** — текстка өстәмә аңлатма бирү. Кайбер документта аны төзүнең нигезен күрсәтү сорала.

«Кушымта», «искәрмә», «нигез(ләү)» сүзләре билгеләнгән тәртиптә языла.

Җитәкче документның төп текстына параллель язылган «Адресат» реквизиты сүзе астына кулдан үзенең **резолюциясен** сала.

**Башкаручының фамилиясе һәм телефон номеры** җибәрелә торган документның соңгы битендә күрсәтелә.

Кергән документларның **үтәлеше хакындагы билге** документның беренче битендәге аскы сул почмагына куела.

**Күчермә** — документның бөтен реквизитларын да кабатлау, ул җитәкче рөхсәте белән генә бирелә.

**Документтан файдалану мөмкинлеген чикләү турындагы гриф** документның баш исеме өлешендә «Адресат» яисә «Раслау грифы» реквизиты өстендә куела.

### Предприятие документлары бланклары

Предприятие бланклары типография алымы белән яисә шәхси компьютер ярдәмендә әзерләнә; үзенең реквизитлары булып, алар билгеле бер тәртиптә урнаштырыла.

Бланклар өчен А4 (210ә297 мм) һәм А5 (148ә210 мм) форматындагы кәгазьләр кулланыла.

Предприятие өчен, аның структур бүлекчәсе, урындагы заты өчен документ бланкларының түбәндәге төрләрен куллану тәкъдим ителә:

— гомуми бланк;
— хат бланкы;
— конкрет документ төре бланкы (хаттан гайре).

Гомуми бланк хаттан башка теләсә кайсы документ төрен төзү өчен файдаланылырга мөмкин. Ул түбәндәге реквизитларны үз эченә ала:

— Россия Федерациясенең Дәүләт гербы (Россия Федерациясе субъектының яки шәһәренең гербы);
— оешма эмблемасы яки товар билгесе (хезмәт күрсәтү билгесе);
— югары оешма билгесе (булган очракта);
— оешма (предприятие) исеме.

Гомуми бланкларда документ датасы һәм теркәү номеры кебек реквизитларның трафарет өлешләрен күрсәтү рөхсәт ителә, мәсәлән # .

Гомуми бланкларда түбәндәге документ реквизитлары өчен буш дүртпочмаклыклар калдыру тәкъдим ителә:

— раслау грифы;
— текстның баш исеме;
— контроль турында билге.

Хат бланкы түбәндәге реквизитларны эченә ала:

— Россия Федерациясенең Дәүләт гербы, Россия Федерациясе субъекты яки шәһәре гербы (мондый герб моңа хокукы булган оешмаларга да кагыла);
— оешма эмблемасы яки товар билгесе (хезмәт күрсәтү билгесе);
— оешма (предприятие) коды (ОКПО буенча);
— югары оешма исеме (булган очракта);
— оешма (предприятие) исеме;
— оешма турындагы белешмә мәгълүматлар (адресы, телефон, телефакс номерлары).

Хат бланкларында түбәндәге реквизитларның трафарет өлешләре күрсәтелә: дата, документның теркәлү номеры, теркәлү номерына һәм датасына сылтама, мәсәлән: # ; датадан # га.

Хат бланкларында түбәндәге реквизитлар өчен буш дүртпочмаклыклар калдырыла:

— адресат;
— текстның баш исеме;
— контроль турында билге.

Конкрет документ төре бланкы (хаттан тыш) гомуми бланк нигезендә төзелә, шул ук реквизитларны үз эченә ала һәм бары тик документның тиешле төренә туры килгән исеме генә өстәп язылы, мәсәлән: БОЕРЫК, КҮРСӘТМӘ һ.б.ш.

Эш практикасында предприятие, оешма, ведомство җитәкчеләренең бланклары — вазифаи бланклар кулланыла. Андый бланкларда эш урыны күрсәтелә. Мәсәлән, «Россия Федерациясенең Федераль чик буе хезмәте директоры», «РЕАЛ» ЯАҖ генераль директоры» һ.б.ш.

Бланкта реквизитларны урнаштыруның ике төп варианты мәгълүм: озынча (бит буенча) урнаштыру; почмакка урнаш- тыру.

Озынча бланк документның реквизитларын кәгазь битенең нәкъ уртасына, ягъни ике яктан да тигез ара калдырып, өске өлешенә урнаштыруны күз алдында тота.

Почмак бланкында реквизитлар битнең югары сулъяк почмагында урнаштырыла.

Барлык бланкларда да кырыйлардан түбәндәгечә буш урын калдырыла (миллиметрларда):

— сул яктан — 20;
— өске яктан — 20;
— уң яктан — 10;
— аскы яктан — 10.

ОЕШТЫРУ-БОЕРУ ДОКУМЕНТЛАРЫ

## Оештыру документлары

Оештыру документларына низамнамәләр (уставлар), нигезләмәләр, тәгълимнамә һәм кагыйдәләр керә.

**Низамнамә** (устав) — оешма, учреждение эшчәнлеген, аларның башка оешмалар һәм гражданнар белән үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу кагыйдәләре җыелмасыннан, дәүләт идарәсенең билгеле бер өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлардан гыйбарәт. Гомуми низамнамәләр (уставлар) дәүләт хакимияте һәм идарәсенең югары органнары тарафыннан раслана, ә иҗтимагый оешмалар низамнамәләре (уставлары) аларның съездлары тарафыннан кабул ителә һәм раслана.

**Нигезләмәләр** — дәүләт органнары системасын, бер органны, структура бүлекчәсен оештыру тәртибен, структурасын, эшчәнлеген, вәкаләтен, бурычларын һәм эшен оештыру тәртибен билгелүче җыелма норматив актлар. Нигезләмәләр урындагы затлар эшчәнлеген дә тәртипкә салалар. Тәгаенләнгән мәсьәлә буенча оештыру, хезмәт һәм башка мөнәсәбәтләр җыелмасын җайга салучы нигезләмәләрне аерым төркемгә тупларга кирәк.

Низамнамәләр (уставлар) һәм нигезләмәләр катлаулы документлардан санала. Алар оештыру-боеру документларының бердәйләштерелгән системасы составына керәләр һәм текстның билгеләнгән структурасы кысаларында язылалар.

**Тәгълимнамәләр** — учреждение, оешма, предприятиеләр, урындагы затлар һәм гражданнар эшчәнлегенең оештыру, финанс, фәнни-техник, технология якларын җайга салучы кагыйдәләрне билгеләү максатында басыла яки раслана торган хокукый актлар.

Учреждениенең (оешманың) һәр хезмәткәренә, шул исәптән сәркатибенә дә, вазифаи тәгълимнамә языла. Тәгълимнамә гомуми бланкта тутырыла һәм махсус боеру акты белән яки турыдан-туры җитәкче тарафыннан раслана. Тәгълимнамәдә, боеру документларына кушымта, дигән язу да булырга мөмкин.

## Боеру документлары

Барлык боеру документлары законнарга катгый яраштырылган булырга тиеш. Боеру документларын әзерләү түбәндәге баскычлардан тора:

— мәсьәләнең асылын өйрәнү;
— документ проектын әзерләү;
— документны килештерү;
— документка кул кую (раслау).

Карарлар өчен тикшерү һәм бу документларны кабул итү баскычы да өстәлә.

Боеру документлары төрләре:

**Карар** (постановление) — мөһим мәсьәләләрне хәл итү максатыннан югары һәм үзәк идарә органнары кабул итә торган хокукый акт.

**Карар** (решение) — җирле хакимият органнары кабул итә торган хокукый акт. Бу төр карарлар белән коллегиаль органнар, министрлыклар коллегияләре һәм башка шундыйлар эшчәнлеге нәтиҗәләрен рәсмиләштерәләр.

**Әмер** — дәүләт идарәсенең хакимият дәрәҗәсендәге, әмер бирелгән гражданнар һәм оешмалар өчен мәҗбүри көчкә ия булган акты. Әмер ике төркемгә бүленә: дәвамлы гомуми әмер һәм тәгаенләнгән тар мәсьәләгә кагылышлы әмер.

**Боерык** — дәүләт идарәсе органы (аның структур бүлекчәсе) җитәкчесе чыгара торган хокукый акт. Боерык, әлеге орган алдында торучы төп һәм ашыгыч мәсьәләләрне хәл итү максатында, шәхси идарә нигезендә гамәлдә йөри. Боерыклар *төп эшчәнлек буенча кабул ителгән* һәм *шәхси состав буенча кабул ителгән* боерыкларга бүленәләр.

Норматив (эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында) һәм шәхси боерык (билгеле бер хезмәткәрне бүләкләү турында) булырга да мөмкин.

Боерыклар предприятиенең эчке документлары бланкында языла. Боерыкта документ төренең исеме, кабул ителгән көне һәм исәп тәртибе (саны) язылган булырга тиеш. Аны кабул иткән вакыт булып җитәкче кул куйган вакыт санала. Боерыкның исәп тәртибе (саны) бер ел дәвамында, гыйнвардан декабрьгә кадәр вакыт эчендә кабул ителгән боерык исәбеннән чыгып билгеләнә. Боерыкның башы булырга тиеш. Аның тексты ике өлештән тора: беренче — *билгеләү* — өлешендә әлеге боерыкны кабул итү нигезе күрсәтелә. Боерык чыгаруның сәбәбе ачык булып, аңлатма соралмаган очракта, билгеләү (констатацияләү) өлешен язмыйлар.

Боерыкның БОЕРАМ дигән сүздән башланган икенче —*боеру* — өлешендә «кемгә?», «нәрсә эшләргә?», «кайчанга кадәр?» дигән сорауларга җавап языла.

Боерык тексты, йөкләмәләр берничә булган очракта, пунктларга бүленә. Һәр пункт кызыл юлдан башлана. Соңгы пунктта әлеге боерыкның тулысынча үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыручы зат яки структур бүлекчә күрсәтелә.

Боерыкларга җитәкче яки аның моңа хокук бирелгән урынбасары кул куя.

### Мәгълүмати-белешмә документлар

Учреждение, оешмалардан җибәрелә һәм аларга керә торган документларның күбесе — мәгълүмати-белешмә документлар. Алар учреждение, оешмалардагы эшләрнең фактик торышы турындагы мәгълүматлардан гыйбарәт. Боларга мәгълүматнамә, аңлатмалар, белешмә, актлар, хат, телеграмма, телефонограммалар керә. Бу документлар, ярдәмче эш кәгазьләре булып саналганга, үтәү өчен мәҗбүри түгел.

**Мәгълүматнамә** — җитәкчегә яки югары оешмага юлланган, язучысы тарафыннан нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәре белән нинди дә булса мәсьәлә җентекләп бәян ителгән документ.

Оешманың үз эчендә йөри торган мәгълүматнамәләр чиста кәгазь битенә кулдан языла һәм текст соңында язучының имзасы, язылган көне куела.

Оешмадан читкә китә торган мәгълүматнамә гомуми бланкка басыла, һәм аңа оешма җитәкчесе кул куя, текстка баш билгеләнә, кул куелган вакыты, оешмадан чыгу саны күрсәтелә.

**Аңлатма** — предприятие хезмәткәре нинди дә булса әмерне, боерыкны, тәгълимнамәне яисә телдән җиткерелгән әмерне үтәмәү, шулай ук эчке тәртип кагыйдәләрен бозу сәбәпләрен аңлаткан документ. Аңлатма чиста кәгазь битенә кулдан языла, имза куелган көне күрсәтелә. Моннан тыш, ул кайбер документларга (хисап һәм актларга) теркәлергә мөмкин.

**Белешмә** — теге яки бу фактлар һәм вакыйгаларны тасвирлаган яисә раслаган документ. Ул югары орган таләбе буенча языла, һәм аңа учреждение җитәкчесе кул куя. Белешмә, кагыйдә буларак, трафарет бланкка языла, учреждение җитәкчесе, баш бухгалтер тарафыннан имза салына һәм герблы мөһер белән раслана.

**Акт** — берничә кеше тарафыннан төзелгән ачык факт һәм вакыйгаларны раслаучы документ. Акт учреждение, оешма, предприятие администрациясе тарафыннан тиешле боеру документларын язу өчен нигез булып тора. Акт гомуми стандарт бланкка языла.

**Эш хатлары** — идарә итү документларының аралашу чарасы буларак файдаланыла торган зур төркеменең гомумиләштерелгән исеме. Хатның эчтәлеге ике өлештән тора. Беренчесендә документны язарга этәргән сәбәпләр күрсәтелсә, икенчесендә документның ни өчен язылуын аңлаткан төп өлеше бәян ителә. Хатлар махсус билгеләнгән бланкка язылалар.

Учреждение, оешмадан читкә китә торган хатлар ике төркемгә бүленә: инициативалы һәм җавап хатлары. Моннан тыш теркәп җибәрелүче хат, чакыру хатлары, мәгълүмат җиткерүче хатлар, реклама хаты, хәбәр хатлары, раслау хатлары, искә төшерү хатлары, гарантия бирүче хатлар да була.

**Телеграмма** — мәгълүматны телеграф элемтәсе каналлары аша тапшыра торган документ. Фототелеграммалар, телеграмма-схема, телеграмма-ышанычнамәләр була. Телеграммалар махсус типография бланкларына языла, аны ике нөсхәдә басалар. Эш телеграммалары тексты мөһер белән раслана.

**Телефонограмма** — телефон аша тапшырыла торган эчтәлекләре төрле документлар исемен гомумиләштерүче документ. Бер нөсхәдә языла.

**Факс** — телефон элемтәсе каналлары аша факсимиль күчермә рәвешендә алынган кәгазьдәге мәгълүмати документ. Факс аша текстлар да, таблица, рәсем һәм теләсә нинди график мәгълүмат та җибәрергә мөмкин. Факс аша җибәрелә торган документлар тапшырыла торган документ төренә куелган таләпләргә төгәл туры китереп язылырга тиеш.

**Беркетмә** — коллегиаль органнар җыелышларында, киңәшмә, конференция һәм утырышларында мәсьәләне тикшерүнең барышын һәм карар кабул итүне теркәүче документ. Язылу ысулы һәм тулылыгы буенча стенографик, фотографик, конспект рәвешендәге һәм кыска (чыгышларның эчтәлеге язылмаган) беркетмәләр була. Даими эшләп торучы коллегиаль органнар утырышларына беркетмә язу мәҗбүри.

Беркетмә язу — сәркатипнең иң әһәмиятле бурычларының берсе. Шуның өстенә сәркатип беркетмәдәге мәгълүматлар эчтәлегенең дөреслеге өчен дә җаваплы. Беркетмә тулы яки кыска булырга мөмкин. Кыска беркетмәдә көн тәртибе, чыгыш ясаучыларның фамилиясе, чыгышлар темасы, кабул ителгән карарлар күрсәтелә, тулы текстлар бирелми. Мондый беркетмәләр мәсьәләне тикшерүнең барышы турында тулы мәгълүмат бирми.

Беркетмә язганда документның тулы юридик кыйммәте турында да онытмаска кирәк. Ул — беркетмәдә кирәкле барлык реквизитларның булуы һәм дөрес язылуы белән билгеләнә.

Югарыда китерелгән документлардан тиешле чыгармалар ясарга була. Чыгарма документ кебек үк языла. Аңа ...ДӘН (ДАН) ЧЫГАРМА дигән баш куела, һәм предприятие, учреждение җитәкчесе тарафыннан имза салынмый.

## ДОКУМЕНТЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮНЕ ОЕШТЫРУ

Мәгълүмат һәм документлар белән тәэмин итү идарә итүнең мөһим хезмәт күрсәтү эшчәнлеге булып тора. Ул барлык нечкәлекләрне исәпкә алып башкарылырга тиеш. Әлеге эшчәнлекне эре учреждениеләрдә махсус структура бүлекчәләре (эш башкару бүлеге, гомуми бүлек, секретариат, канцелярия) башкара. Кече предприятиеләрдә исә бу эш белән сәркатипләр шөгыльләнә.

Документлар белән эш итү тәртибе, аларны төзү һәм язу норматив-ысулый документларда җентекләп бәян ителә.

### Документлар әйләнеше турында төшенчә

Документлар әйләнеше — учреждениедә документның язылган вакытыннан алып төгәлләү, башкару һәм юллау вакытына кадәр әйләнештә булуы.

Учреждениедә документлар әйләнешен оештыру түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

— документларның әйләнештә йөреше ашыгыч, максатчан булырга һәм җайга салынырга, тиз арада башкарылырга;

— документларның кире әйләнеп кайтуын булдырмаска тырышырга;

— документларның мөмкин булган кадәр бердәйлегенә ирешергә кирәк. Бу максатларда документларның төп категорияләрен әйләнештә йөртү һәм эшкәртүнең якынча схемасын эшләү тәкъдим ителә.

Учреждениедә документлар әйләнеше документлар агымы рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Документлар агымының төп өч төрен билгелиләр:
— керүче — учреждениегә керүче документлар;
— китүче (чыгучы) — учреждениедән башка оешмаларга китүче документлар;
— эчке — учреждениенең үзендә язылучы һәм аннан читкә китми торган документлар.

Документлар агымы белән эш өч юл белән алып барыла:
— үзәкләштерелгән (документлар әйләнеше зур булган учреждениеләрдә);
— үзәкләштерелмәгән;
— катнаш (катлаулы структуралы һәм документлар әйләнеше зур булган эре предприятие һәм учреждениеләрдә кулланыла).

Документлар белән эш итү рәвешен сайлаганда, түбәндәге факторларны исәпкә алырга кирәк:
— документлар әйләнеше күләмен;
— предприятиенең эшчәнлек рәвешен;
— предприятие һәм аның бүлекчәләре структурасын;
— техника белән җиһазлану дәрәҗәсен;
— җитәкчеләрнең белем дәрәҗәсен һ.б.ш.

Документлар әйләнешенең күләменә карап, предприятиеләр 4 категориягә бүленә:
— I категория — әйләнештә елына 100 000 нән дә артык документ йөри;
— II категория — әйләнештә елына 25 000 нән 100 000 гә кадәр документ йөри;
— III категория — әйләнештә елына 10 000 нән 25 000 гә кадәр документ йөри;
— IV категория — әйләнештә елына 10 000 гә кадәр документ йөри.

Документлар әйләнеше барышында алар белән эшләүнең төп этаплары:
— документларны кабул итү һәм беренчел эшкәртү;
— документларны алдан карап чыгу һәм юнәлешләре буенча тарату;
— теркәү;
— үтәлешен тикшерү;
— мәгълүмат-белешмә эшләре;
— документлардагы мәсьәләләрне хәл итү һәм тиешле урынга юллау.

## Документларны кабул итү һәм беренчел эшкәртү

Документлар, үзәкләштерелеп, сәркатип тарафыннан кабул ителә һәм беренчел эшкәртелә. Эре предприятие, учреждениеләрдә исә бу эшләрне экспедицияләр (экспедиторлар) башкара.

Документлар почта, телетайп, факс, электрон почта аша һәм эш кәгазьләрен йөртүче йомышчылардан алынырга мөмкин.

Документларны кабул итеп алганда, аларның дөрес җибәрелүе һәм тапшырылуы, эчендәге кәгазьләрнең саклanganлыгы, бөтенлеге тикшерелә. Учреждениегә керүче документларның барысына да аларның кергәнлеге турында билге ясала. Бу билге документны кабул итеп алган вакыттан һәм агымдагы ел дәвамында кергән документларның гомуми санын күрсәтүче исәпкә кергән тәртип саныннан гыйбарәт.

Әгәр документлар почта аша килсә, «Шәхси» дип язылганнарыннан кала, барлык конвертлар да ачыла. Ачылган конвертлар, гражданнарның җавап көтеп язылганнарыннан тыш, юк ителәләр. Документның учреждениегә кергәнлеге штамп белән раслана. Учреждениегә кергән документлар, үз чиратларында, теркәлә һәм теркәлми торганнарга бүленәләр.

## Документларны теркәү

Документларны теркәү — алар белән эшләүнең иң мөһим этабы. Махсус исәпкә алынырга, үтәлергә һәм белешмә максатларында файдаланырга тиешле барлык документларны да теркәү зарур. Теркәү — документ күрсәткечләрен (реквизитларын) алу дигән сүз.

Документлар, үзәкләштерелеп, сәркатип тарафыннан бер мәртәбә теркәлә. Эчке документларны теркәү бүлекләре булган учреждениеләрдә документларны теркәү, үзәкләштерелмичә, бүлекләрнең үзендә (бухгалтериядә, кадрлар бүлегендә, канцеляриядә) башкарыла.

Эчке документлар — кул куелган һәм расланган көнендә, учреждениегә килгән документлар — кергән көнендә, учреждениедән китә торганнары җибәрелгән көнендә теркәлергә тиеш.

Теркәгән чакта документтан түбәндәге мәгълүматлар күчереп алына:

— кабул итеп алынган көне;
— кергән саны (индексы);
— төп эзләп табу билгеләре (документның язылган көне һәм индексы);
— авторы (документны язучы);
— документның исеме;
— резолюциясе;
— үтәлү вакыты;
— үтәүчесе;
— үтәлү барышы (документның кемнәргә тапшырылганы һәм ничек үтәлүе теркәлеп барыла);
— эшнең саны (үтәлгәннән соң документ куелган эш папкасы).

Теркәү рәвеше өч төрле (кенәгәдә, карточкада һәм электрон (компьютерда) булырга мөмкин.

## Документларның үтәлешен тикшерүне оештыру

Документлардагы тәкъдимнәрнең, йөкләмәләрнең һәм мәсьәләләрнең үтәлеше һәрдаим тикшерүдә булырга тиеш. Бигрәк тә түбәндәге документлар тикшерүдә тотыла:

— учреждениегә керүче;
— учреждениедән чыгучы;
— учреждениенең үз эчендәге (эчке) документлар.

Документларның һәм андагы йөкләмәләрнең үтәлешен җитәкче яки ул вәкаләт биргән кеше тикшерә. Үтәлешне тикшерү документны контрольгә куйган көннән башлана, һәм аны «Тикшерүдә» дигән штамп сугылган теркәү карточкаларында алып бару тәкъдим ителә. Документларны үтәү вакыты бертип һәм шәхси булырга мөмкин.

Бертип үтәү вакыты гамәлдәге законнар нигезендә тикшерүдә тотылырга тиешле документларның аерым категорияләре өчен билгеләнә.

Шәхси үтәү вакыты мөһим документлар өчен учреждение җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, һәм бу дата документның үзенә язып куела.

Документның үтәлү вакыты узып киткән очракта, учреждениенең тикшерү хезмәте тоткарлык сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, документларны үз вакытында үтәүне тәэмин итү өчен чаралар күрергә тиеш.

Тикшерүдә торучы документларның үтәлү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар һәр айның беренче көненә булган хәлендә гомумиләштереләләр һәм учреждение җитәкчесенә җиткереләләр.

I һәм II категорияле учреждениеләрдә документларның үтәлеше турында ай саен мәгълүматнамә төзелә.

III һәм IV категорияле учреждениеләрдә исә документларның үтәлеше турында (тәкъдимнәр, гаризалар һәм гражданнардан килгән хатларның үтәлеше буенча графа белән) бердәй айлык белешмә языла.

Документларны анализлау нигезендә, түбәндәге тәкъдимнәр эшләнә:

— документларның үтәлешен тизләтү;
— үтәү дисциплинасын яхшырту;
— тикшерүне оештыруны һәм, гомумән, идарә итүне камилләштерү турында тәкъдимнәр.

## Учреждениегә керүче документлар белән эшләүнең блок-схемасы

Конвертларны кабул итү, адреслауның дөреслеген тикшерү

Хатларны «Шәхси» билгесе белән фирма хезмәткәрләренә тапшыру
Конвертларны ачу һәм андагы документларны тикшерү

Башлангыч тикшерү
(төрләргә аеру, билгеләү)

Документка керүе турында билге ясау (штамп кую)

Теркәү

Документларны
җитәкчегә бирү
(доклад)

Документларны
җитәкченең каравы
(резолюция)

Резолюция мәгълүматын теркәү кенәгәсенә кертү

Документларны
башкаручыга тапшыру

Документларның
үтәлешен тикшерү

Документларның үтәлеше

Документларны
эш папкасына тегү
Документларны
директор урынбасарына,
структур бүлекчәләргә
яки башкаручыга тапшыру

## Белешмә аппаратын төзү

Сәркатипнең документлар белән агымдагы эшендә шактый урынны документларны эзләү, аларны үтәүнең барышын тикшерү, белешмә бирү эшләре алып тора.

Шул максатка белешмә-мәгълүмат картотекасы хезмәт итә. Әлеге картотека сәркатипнең эш өстәлендә уң якта кул сузымы ераклыгында куела. Бу — тиешле карточканы тиз генә табарга һәм телефон аша җиткерелгән үтенечкә белешмәне тоткарлыксыз бирергә ярдәм итә.

Белешмә картотекасы ике өлешкә: үтәлгән һәм үтәлмәгән документларга бүленә.

Картотеканың беренче өлеше документны үтәү барышында аны эзләү өчен билгеләнә. Бу өлештә документны үтәүче структур бүлекчәләр, фамилияләр язылган була.

Тикшерү картотекаларында документлар үтәү вакыты буенча да бүленәләр.

Картотеканың икенче өлеше билгеле бер мәсьәлә буенча үтәлгән документны эзләү максатында файдалану өчен төзелә.

Гаризалар, тәкъдимнәр һәм гражданнардан кергән шикаятьләрдән торган картотека төп картотекадан аерым алып барылырга мөмкин.

Кирәк булган очракта, махсус картотека булдырыла. Аны кайчакта вакытлы картотека дип тә йөртәләр. Бу картотека 12 ояга бүленгән әрҗә рәвешендә эшләнә. Һәр ай, оясы, ай көннәре күрсәтелеп, янә 31 (30, 28, 29) өлешкә бүленә.

Мәгълүмат-белешмә хезмәте күрсәтү мөмкинлекләре, теркәүнең автоматлаштырылган системасын кертү белән, тагын да киңрәк тарала бара.

## Документларны җибәрү

Предприятие, учреждениедән читкә китүче документларны эшкәртү һәм юллау, керүче документларны кабул итү һәм эшкәртү кебек үк, сәркатип (экспедитор) тарафыннан үзәкләштерелеп гамәлгә ашырыла.

Кая да булса җибәрү өчен документны алганнан соң, аның дөрес язылуын (тутырылуын) билгеләү максатында, түбәндәгеләрне тикшерәләр:

— имза куелганмы;
— көне язылганмы;
— исеме (башы) бармы;
— барлык битләре дә кергәнме;
— адресатлары дөрес язылганмы.

Җибәрелә торган документ конвертка салына. Конвертларга адрес языла һәм штамп сугыла. Документларны җибәрү өчен әзерләү почта кагыйдәләре таләпләренә катгый туры китереп башкарыла.

Соңгы елларда документларны электрон почта аша тапшыру да гадәткә кереп бара.

## ШӘХСИ СОСТАВ ДОКУМЕНТЛАРЫ

Хезмәткәрләрне эшкә кабул итү, эштән азат итү, бер эштән икенчесенә күчерү, чираттагы ялын бирү, бүләкләү вакытында язылган документлар шәхси состав документлары төркемен тәшкил итәләр.

Аларга түбәндәгеләр керә:

— хезмәт килешүе (шартнамә);
— шәхси состав буенча әмерләр (боерыклар);
— хезмәт кенәгәләре;
— Т-2 формасындагы шәхси таныклыклар;
— шәхси эшләр;
— эш хакы буенча шәхси хисаплар.

Шәхси состав документларын язу аеруча җентеклелекне һәм төгәллекне таләп итә.

## Хезмәт килешүе

Хезмәт килешүе (шартнамә) — якларның хезмәттә билгеләнгән хокук мөнәсәбәтләренә ризалыгын рәсмиләштерүче һәм аларны җайга салучы документ.

Килешүне төзегәндә, түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

— эш урынын;
— тәгаенләнгән эшне;
— эшне башлау һәм тәмамлау көнен;
— эш өчен түләүне;
— предприятиенең хезмәт иминлеген тәэмин итү бурычларын.

Даими эшкә алганда, документ түбәндәге схема буенча язылырга тиеш:

Хезмәткәр белән төзелгән
хезмәт килешүе (шартнамә)

Эшкә кабул итү турында әмер

## Шәхси состав буенча әмерләр (боерыклар)

Шәхси состав буенча әмер белән хезмәткәрләр эшкә алына, эштән азат ителә һәм бер эш урыныннан икенчесенә күчерелә. Шәхси состав буенча әмерләр аерым бер эш (дело) булып туплана һәм Ш/Х яки К (Шәхси хисап яки Кадрлар) индексы белән мөстәкыйль исәп алып бару өчен махсус нумерлана.

Шәхси состав буенча әмерләр предприятиеләрнең эчке документлары бланкларына языла. Әмер тексты ике өлештән: билгеләү һәм боеру өлешеннән тора. Икенче өлеш БИЛГЕЛӘРГӘ, АЗАТ ИТӘРГӘ, КҮЧЕРЕРГӘ дигән сүзләргә тәмамлана.

Шәхси состав буенча әмерләр 75 ел дәвамында (әмма бу саннан хезмәткәрләрнең яше алынырга тиеш) саклана.

## Хезмәт кенәгәсе

Хезмәт кенәгәсе өзлексез гомуми һәм махсус хезмәт стажын раслаучы төп документ булып тора. Алар һәр предприятие, учреждениедә һәр хезмәткәргә тутырыла.

Учреждениедә төп эшендә кимендә биш көн эшләгән һәр хезмәткәргә, шул исәптән вакытлы эшчеләргә дә тутырыла.

Әмер (боерык) чыкканнан соң, кабул итү, башка даими эшкә күчерү, эштән алу, бүләкләү һ.б.лар турында хезмәт кенәгәсенә язылырга, һәм бу язмалар әмер (боерык) текстына төгәл туры килергә тиеш.

Хезмәт кенәгәсе, катгый хисаплылык документы буларак, сейфта саклана.

Кулга бирелә торган хезмәт кенәгәсендә, эштән алуның сәбәбе һәм көне күрсәтелеп, хезмәт эшчәнлегенең туктатылуы турында язып куела.

Хезмәткәр, эштән азат ителгәндә һәм хезмәт кенәгәсен үз кулына алганда, исәп кенәгәсенә имзасын куеп калдыра.

## Шәхси кенәгә

Т-2 формасындагы шәхси кенәгә предприятие хезмәткәрләре исәбен алу буенча төп документ булып тора. Шәхси кенәгә, төгәл һәм аңлаешлы итеп, кадрлар бүлеге хезмәткәре тарафыннан, эшкә алынган барлык хезмәткәрләргә бер нөсхәдә тутырыла. Шәхси кенәгәдәге барлык язмалар, бернинди кыскартылуларсыз, тулысынча языла. Шәхси кенәгә хезмәткәр турындагы барлык мәгълүматны үз эченә ала.

Автоматлаштырылган системада хезмәткәр турындагы мәгълүмат шәхси компьютерга кертелергә һәм аның нигезендә Т-2 формасы бастырып алынырга мөмкин. Бу — оешма яки фирманың шәхси составы буенча теләсә нинди хисап-белешмә документларын язарга мөмкинлек бирә.

## Шәхси эштә документлар составы һәм аларны урнаштыру эзлеклелеге

Учреждение, предприятиенең кадрлар бүлегендә һәр хезмәткәргә, эшкә алу турында әмер (боерык) чыкканнан соң, шәхси эш ачыла. Вакытлы эшкә алынганнарга, хезмәт күрсәтүче кече хезмәткәрләргә һәм эшчеләргә шәхси эш ачылмый, аларга бары тик Т-2 формасындагы шәхси кенәгә генә тутырыла.

Шәхси эш хезмәткәр турында шактый тулы мәгълүмат бирүче документлар җыелмасыннан гыйбарәт.

Шәхси эш документлары составына түбәндәгеләр керә:

— шәхси эшкә кертелгән документлар исемлеге;
— эшкә кабул итүне сорап язган гариза, юллама яки тәкъдимнамә;
— анкета яки кадрларны исәпкә алу буенча шәхси бит;
— тәрҗемәи хәл;
— белем турында документлар күчермәсе;
— тасвирнамә;
— әмерләрдән (боерыклардан) чыгарма;
— кадрларны исәпкә алу буенча шәхси биткә өстәмә;
— бүләкләүләрне исәпкә алу буенча шәхси эшкә өстәмә;
— бу хезмәткәргә кагылышлы белешмәләр һәм башка документлар.

Әлеге документларның барысы да аерым папкага салынып, тегеп куела. Аның тышлыгы дәүләт стандартлары таләпләренә туры китереп бизәлергә, язылырга тиеш.

Шәхси эшкә түбәндәгеләр кертелми:

— тору урыныннан белешмә;
— сәламәтлек турында медицина белешмәсе;
— кисәтүләр ясау, бүләкләү, фамилиясен үзгәртү турындагы әмерләрдән (боерыклардан) чыгарма.

Хезмәткәрнең хезмәт эшчәнлеге барышында аның шәхси эше белеменең, гаилә хәленең һ.б. үзгәрүен раслаучы башка документлар белән дә тулыландырылырга мөмкин.

Эштән бушатыла торган хезмәткәрләрнең шәхси эшләре ел ахырында исемлек буенча учреждение архивына яки шәхси состав буенча ведомствоара архивка тапшырыла. Бу очракта аларның битләре нумерлана.

### ДОКУМЕНТЛАРНЫ ЭШ БАРЫШЫНДА САКЛАУ

Эш барышында предприятиеләр күп сандагы документлар белән эш итәләр.

Файдаланганнан соң аларны туплау һәм саклау мәсьәләсе килеп туа.

Төгәл классификация булганда гына документларны тиз арада эзләп табуга һәм алардан файдалануга ирешергә мөмкин. Документларны төркемнәргә бүлеп төпләү — классификацияләүнең иң гади төре.

Документларны төркемнәргә бүлү тәртибен билгели торган махсус классификатор эш номенклатурасы дип атала.

## Эш номенклатурасы

Эш номенклатурасы — эш атамаларының саклау вакыты күрсәтелгән, системалаштырылган исемлеге ул.

Эш номенклатурасы түбәндәгеләр өчен хезмәт итә:

— башкарылган документларны бүлү һәм төркемләү өчен;
— эшләрнең индексацияләрен билгеләү өчен;
— башкарылган документларга белешмә картотекасын булдыру максатында; ул исә учреждение архивында вакытлыча саклана торган эшләр өчен исәпкә алу документы булып тора.

Эш номенклатурасы түбәндәгеләргә бүленә:

— индивидуаль эш номенклатурасы (конкрет учреждение документлары);
— бертөрле эшчәнлек белән шөгыльләнүче һәм охшаш документлар составы белән эш итүче категориядәге учреждениеләрнең документларын төркемләүне камилләштерү максатында үрнәк һәм бертип эш номенклатурасы (мәктәпләр, ПТУлар һ.б.ш.).

Үрнәк эш номенклатурасы тәкъдим итү рәвешендә була. Ә бертип эш номенклатурасы мәҗбүри үтәлергә тиеш.

Эш номенклатурасы төзегәндә төп принциплар түбәндәгеләр:

— документларны исәпкә алу, системалаштыру, тасвирлау һәм эзләү эшен җайга салу;
— документлар өчен үрнәк индексация, ул номенклатураның тиешле бүлегенә үзгәрешләр, өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертүне тәэмин итә;
— эш индексларының тотрыклылыгы;
— эш номенклатурасы белән документларны исәпкә алу функциясенең сакланышы.

Эш номенклатурасына түбәндәгеләр керә:

— документларга кагылышы булган хезмәтләрнең эшләре һәм документлары, учреждение эшчәнлегенең кайбер мәсьәләләрен чагылдыручы эшләр һәм документлар;
— документлары учреждение вәкаләтләрен раслау яисә аның эшчәнлеген туктату өчен хокукый нигез булып хезмәт итүче вакытлыча гамәлдәге органнарның эшләре;
— эшләүне дәвам итү өчен башка учреждениедән алынган, үтәлеп бетмәгән эшләр;
— документларга карата барлык белешмә картотекалар.

Структур бүлекчәнең эш номенклатурасын сәркатип яисә документлар белән эш итүгә җаваплы зат төзи һәм имза сала, учреждение җитәкчесе раслый һәм учреждениенең архивы белән килештерә.

Җыелма эш номенклатурасын канцелярия башлыгы имзалый һәм килештерә, учреждение җитәкчесе раслый.

Эш номенклатурасының классификация схемасын сайлау учреждение аппаратының оештыру-структур төзелешен һәм алар башкара торган вазифаларны исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш.

## Эшләрне берләштерү

Учреждениеләрдә, фирмаларда башкарылган документлар күп тупланганлыктан, тиз генә ачыклау һәм кирәкле мәгълүматны табу өчен аларны төркемнәргә бүләләр, ягъни аерым папкаларга салалар.

Эшләрне берләштерү документларны эшләр буенча бүлүне, бу эш буенча документларны системалаштыруны аңлата. Документларны бүлү эш номенклатурасы нигезендә башкарыла.

Эшләрне берләштерүне, туплауны һәм саклауны оештырганда, түбәндәге норматив документлардан файдалану зарур: «Ведомство архивларының төп эш кагыйдәләре»; «Идарә итүне документлар белән тәэмин итүнең дәүләт системасы».

Эшләрне документлар җыелган структур бүлекчәләрдә туплыйлар һәм саклыйлар.

Боеру документлары, җитәкчелекнең хатлары һәм башка мөһим эчке документлар канцеляриядә яисә җитәкчелек секретариатында саклана.

Кечкенә учреждениеләрдә, фирмаларда эшләрне, үзәкләштереп, сәркатип туплый һәм саклый.

Эшләрне берләштерүгә ел башыннан ук керешәләр. Ел башыннан ук төрле эш папкалары булдырылырга тиеш. Һәр эш папкасының тышында учреждение, фирма исеме языла. Тышлыктагы исем, гадәттә, тулысынча номенклатурадан күчереп языла. Тышлыкның аскы өлешендә саклау вакыты күрсәтелә. Документларны эш папкаларына бүлүне ел дәвамында сәркатип яисә әлеге эш өчен җаваплы зат башкара.

Номенклатурада каралмаган документлар барлыкка килгән очракта, мөстәкыйль эш папкасы ачыла, аның исеме эш номенклатурасына резерв номер белән өстәп языла.

Документны эш папкасына теккәнче, аның үтәлешен карарга кирәк (бу хакта билге булырга тиеш). Документлар папкага бер нөсхәдә генә тегелә, ә аеруча кыйммәтле документларның караламалары исә искәрмә рәвешендә кертелә. Һәр эш папкасының калынлыгы 30—40 мм дан, ә күләме 250 биттән дә артмаска тиеш.

Документлар папкаларга бер календарь ел өчен генә туплана. Күчерелмә эшләргә, суд эшләренә һәм шәхси эшләргә бу кагыйдә карамый.

Мәсьәләне хәл итү барышында килеп туган кушымталар һәм өстәмә материаллар документлар белән бергә урнаштырыла. Эш папкасындагы документлар эчтәлеге, хронологиясе буенча, алфавит тәртибендә һәм нумерланып системалаштырыла.

Боеру документлары документ төрләре һәм хронологиясе буенча берләштерелә. Төп эшчәнлек турындагы боерыклар шәхси состав хакындагы боерыклардан аерым төркемләнә.

Коллегия документлары ике төрле эш папкасына бүленә:

— коллегия беркетмәләре һәм карарлары;
— коллегия утырышларына документлар (көн тәртибе, докладлар, белешмәләр, бәяләмәләр, карар проектлары һ.б.). Хат-хәбәрләрне хронологик эзлеклелектә системалаштыралар, җавап документы үтенечнамәдән соң тегелә. Инициатива документларында да хронология саклана.

Халыкка мөрәҗәгатьләр буенча эшләр гомуми хат-хәбәрләрдән аерым туплана.

### Эш папкаларын саклау

Эш папкалары — нинди дә булса билге буенча тупланган һәм тышлыкта искәртелгән документлар җыелмасы.

Беренче башкару документы кертелгән мизгелдән эш папкасы ачылган дип санала. Ул бүлекчәдә төзелә һәм учреждениенең архивына тапшырылганчы шунда саклана. Эш папкалары, тизрәк эзләп табуны тәэмин итү өчен, бикләнә торган шкафларда, шүрлекләрдә вертикаль сакланырга тиеш. Аларны номенклатурадагыча итеп урнаштыру мөһим.

Документны эзләгәндә, башта — номенклатура буенча кирәкле номер, аннары, шул документ номеры буенча, эш папкасы эзләп табыла.

Аеруча кыйммәтле документларны туплаган эш папкасы өчен эчке тасвирлама төзелә, анда һәр документ языла. Тасвирлама эш папкасының беренче битендә урнаштырыла һәм анда документның индексы, датасы, эчтәлеге, бит саны күрсәтелә.

Әгәр документ папкадан алынса, аның урынына документ-ның кайчан һәм ни өчен алынганлыгы турында язма кыстырып куела.

Әгәр эш папкасын тулысынча бирү таләп ителсә, махсус карта тутырыла, анда эш папкасының номеры, бирү көне, кемгә, күпме вакытка бирелгәнлеге, бирү һәм кабул итеп алу турында язылып, имзалар күрсәтелә.

Эш башкару елы тәмамланганнан соң, папкадан кайбер документларны гына биреп тору тыела. Ә инде бик кирәк булган очракларда, эш папкасы, вакытлыча файдалану өчен, тулысынча бирелергә мөмкин.

### ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН САКЛАУ<br>ҺӘМ ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН ӘЗЕРЛӘҮ

Документлар белән эшләүнең соңгы этабы — аларны алга таба саклау һәм файдалану өчен эшкәртү.

Структура бүлекчәләрендә документ агымдагы ел тәмамланганнан соң тагын бер ел сакланырга тиеш. Бу вакыт чыккач, документлар дәвамлы саклау өчен эшкәртелергә һәм учреждение архивына тапшырылырга тиеш.

Озак саклау өчен документлар түбәндәгечә эшкәртелә:
— документларның фәнни һәм гамәли кыйммәтен билгеләү өчен экспертиза ясала;
— эшләр тиешенчә әзерләнә;
— вакытлыча һәм даими сакланырга тиешле документларның исемлеге төзелә;
— эшләр архивка тапшырыла һәм кабул ителә.

Документларның кыйммәтен билгеләү өчен экспертиза өч этапта ясала.

Беренче этап — документлар белән агымдагы эш стадиясендә, икенчесе — документлар белән эшләү тәгәлләнгәннән соң аларны ведомствога караган архивка тапшыру өчен әзерләү стадиясендә, өченче этап аларны дәүләт архивына саклауга тапшыру өчен әзерләгән вакытта үткәрелә.

Саклау өчен документларның төп нөсхәсе сайлап алына.

Документаль материалларны саклау вакытын күрсәтеп архивка тапшыру кыйммәтле документларның яхшы сакланылышын тәэмин итә. Экспертлар комиссиясе документлар кыйммәтен билгели. Мондый комиссияләр илнең барлык учреждениеләрендә дә төзелә. Алар кимендә 3—5 кеше составында учреждение җитәкчесе әмере (боерыгы) белән билгеләнә.

Экспертлар хезмәте эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдән тора:

— документларны даими сайлап алу һәм аларны дәүләт архивына саклауга тапшыру өчен әзерләүне тәэмин итү эшләрен оештыру;
— документларны сайлап алу һәм учреждениенең үзәк аппаратында оештыру эшләрен ысулый яктан тәэмин итү;
— структура бүлекчәләренең экспертлар комиссиясе эшчәнлегенә оештыру-ысулый җитәкчелекне һәм аны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру.

Экспертлар комиссиясе эшчәнлегенә ысулый ярдәмне һәм аны тикшерүдә тотуны учреждение архивы хезмәткәрләре башкара.

Документларны саклауның тәгаенләнгән вакыты «Саклау вакыты күрсәтелгән документлар исемлеге һәм предприятие эшләренең номенклатурасы» буенча билгеләнә. Документларның әһәмиятлелегеннән чыгып, түбәндәге саклау вакытлары күрсәтелә: 6 ай; 1 ел; 3 ел; 5 ел; 15 ел; 50 ел; 70 ел һәм даими саклау.

Даими сакланырга тиешле документларга предприятиенең шәхси составы документлары уставлары, директорлар советы утырышлары, гомуми җыелышлар беркетмәләре, еллык планнар һәм хисаплар, эш хакы буенча шәхси хисаплар, Т-2 формасындагы шәхси кенәгәләр, хезмәткәрләрне исәпкә алу кенәгәсе керә. Эш хакы буенча шәхси хисаплар 75 ел дәвамында (әмма бу саннан хезмәткәрнең яше алынырга тиеш) саклана.

Экспертлар комиссиясе документларны 3 төркемгә бүлә: архивта сакланырга тиешле, эш башкару өлкәсендә алга таба файдаланырга һәм юкка чыгарылырга тиешле документлар.

Архивта саклау өчен сайлап алынган документлар өстәмә эшкәртүне таләп итә:

— документлар хронологик тәртиптә урнаштырыла;
— эш кәгазе битенә өске уң почмакка тәртип саны куела;
— эш кәгазьләре ахырына битләр саны күрсәтелгән раслау бите теркәлә;
— әһәмиятлерәк документлар өчен эшнең үз эчендәге документларның исемлеге төзелә;
— эш кәгазьләре төпләнә яки дүрт җирдән тегеп куела;
— эшләрнең тышлыгында, раслау кәгазе нигезендә, битләр саны, эшнең саклану вакыты өстәмә рәвештә күрсәтелә.

Вакытлыча (10 елга кадәр) сакланырга тиешле эшләрне эш кәгазьләрен теркәү папкаларында текмичә һәм битләр санын куймыйча саклау рөхсәт ителә.

